# КИТАПХАНӘ ХӘБӘРЛӘРЕ

Фәнни-гамәли журнал

2 (42) 2016

Научно-практический журнал

# БИБЛИОТЕЧНЫЙ ВЕСТНИК



РБА
РОССИЙСКАЯ
БИБЛИОТЕЧНАЯ
АССОЦИАЦИЯ

*ЗА ВКЛАД
В ПРОДВИЖЕНИЕ
ПРОФЕССИОНАЛЬНОЙ
КНИГИ*

# ДИПЛОМ

**РОССИЙСКАЯ БИБЛИОТЕЧНАЯ АССОЦИАЦИЯ
НАГРАЖДАЕТ**

УЧАСТНИКА КОЛЛЕКТИВНОГО СТЕНДА РБА
НА XXIX МОСКОВСКОЙ МЕЖДУНАРОДНОЙ КНИЖНОЙ
ВЫСТАВКЕ-ЯРМАРКЕ (7—11 сентября 2016 г.)

**Национальную библиотеку Республики Татарстан**

ПРЕЗИДЕНТ В. Р. Фирсов

2016 г.

БУ САНДА:
В НОМЕРЕ:

*Сәгъдәтшин И.* Татарстан китап нәшрияты милләтебез, телебез сагында ........ 2
*Сагдатшин И.* Татарское книжное издательство за сохранение нации и языка ........ 2

**Республика китапханәләрендә**
**В библиотеках республики**

*Эркаева Г.* Счастлив библиотекарь – счастлив читатель ........ 6
*Василенко Е.* Есть такая библиотека ........ 8
*Камбиева Р.* Тукай китапханәсенең хәзерге көне ........ 11
*Харисова И.* Исемең калды моңлы бер җыр булып үзеңнән соң килгән буынга ........ 17
*Харисова И.* Үз эшләренең чын осталары ........ 19

**Якутлар табыладыр вакыт белән**
**Наследие**

*Елизарова Р.* Национальная библиотека Республики Татарстан встречает гостей: Потомки династий Второвых и Ушковых посетили библиотеку ........ 21
*Юнусова Р.* О некоторых прижизненных изданиях русских классиков в фондах Национальной библиотеки Республики Татарстан ........ 24
*Мишкинене Г.* Новая рукопись литовских татар в Национальной библиотеке Республики Татарстан ........ 28

**Нәшрият эшчәнлеге**
**Издательская деятельность**

*Галиасфарова А.* Издательская деятельность региональных библиотек ........ 34

**Заман һәм шәхесләр**
**Время и люди**

*Нәҗмиев Т.* Тел – милләт сакчысы (Академик Әбрар Кәримуллинның туган ягына язган хатлары) ........ 37

**Китап һәм балалар**
**Книга и дети**

*Галкина Д.* Подарим детям радость ........ 49

**Социологик тикшеренүләр**
**Социологические исследования**

*Гусева Е., Карабаева М.* «Глобальная сеть: зло или благо?» (Итоги республиканского социологического исследования) ........ 53

**Татарстан китапханәләре хакында вакытлы матбугат**
**О библиотеках Татарстана в периодической печати** ........ 57

**Вакыт-вакыйга**
**Хроника**

*Ширшова В., Гильванов Р.* В Казани появилась библиотека на колесах ........ 62
*Ширшова В.* В Альметьевске появилась уличная библиотека ........ 63
Национальная библиотека РТ – участник семинара для библиотечных работников в Пестречинском муниципальном районе ........ 64

*Тышлыкның беренче һәм дүртенче битләрендә: рәссам И.С. Айдаровның «Казан. Ушкова йорты» картинасы, 2005 ел.*

*На первой и четвертой страницах обложки: картина художника И.С. Айдарова «Казань. Дом Ушковой», 2005 год.*

КИТАПХАНӘ ХӘБӘРЛӘРЕ
№ 2 (42) 2016
ФӘННИ-ГАМӘЛИ ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИЛЛИ КИТАПХАНӘСЕ ТАРАФЫННАН 1996 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП НӘШЕР ИТЕЛӘ. ЕЛГА 2 ТАПКЫР ТАТАР ҺӘМ РУС ТЕЛЛӘРЕНДӘ ЧЫГАРЫЛА.

БАШ МӨХӘРРИР
Р.И. ВӘЛИЕВ
РЕДКОЛЛЕГИЯ:
С.Р. ҖИҺАНШИНА,
И.Г. ҺАДИЕВ
(БАШ МӨХӘРРИР УРЫНБАСАРЫ),
Р.Ә. ХӨСӘЕНОВА
(ҖАВАПЛЫ СӘРКЯТИБ),
А.Р. ГАБДЕЛХАКОВА,
А.Җ. ЗАҺИДУЛЛИН

БИБЛИОТЕЧНЫЙ ВЕСТНИК
№ 2 (42) 2016
НАУЧНО-ПРАКТИЧЕСКИЙ ЖУРНАЛ
ИЗДАЕТСЯ НАЦИОНАЛЬНОЙ БИБЛИОТЕКОЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН С МАЯ 1996 ГОДА. ВЫХОДИТ 2 РАЗА В ГОД НА ТАТАРСКОМ И РУССКОМ ЯЗЫКАХ.

ГЛАВНЫЙ РЕДАКТОР
Р.И. ВАЛЕЕВ
РЕДКОЛЛЕГИЯ:
С.Р. ЗИГАНШИНА,
И.Г. ХАДИЕВ
(ЗАМ. ГЛАВНОГО РЕДАКТОРА),
Р.А. ХУСАИНОВА
(ОТВ. СЕКРЕТАРЬ),
А.Р. АБДУЛХАКОВА,
А.З. ЗАГИДУЛЛИН



**Ильдар САГДАТШИН**,
*генеральный директор*
*Татарского книжного издательства*

# ТАТАРСКОЕ КНИЖНОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО ЗА СОХРАНЕНИЕ НАЦИИ И ЯЗЫКА

Сегодня на страницах печати и в интернете можно видеть немало рассуждений о необходимости сохранения национального языка, культуры, традиций. Но привить любовь к языку, народу, родине нельзя только наставлениями и директивами. Они, разумеется, необходимы, но мало эффективны. В решении этих задач немалая роль отведена художественной литературе. Сколько поколений было воспитано на высоком художественном слове. Формирование духовно-нравственной, всесторонне-развитой личности невозможно без книг, без художественной литературы.

**Илдар СӘГЪДӘТШИН**,
*Татарстан китап нәшриятының*
*генераль директоры*

# ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ МИЛЛӘТЕБЕЗ, ТЕЛЕБЕЗ САГЫНДА

Туган телебез, мәдәниятебез, гореф-гадәтләребезнең сакланышы, яшь буынны милли рухта тәрбияләү турында еш ишетергә, вакытлы матбугат битләреннән һәм интернет сәхифәләреннән еш укырга туры килә. Ләкин ана телен, үз халкыңны, ватаныңны ярату хисе үгет-нәсихәт белән дә, төрледән-төрле директивалар ярдәмендә генә тәрбияләнә алмый торгандыр. Аларның да файдасы бар, ләкин аз дәрәҗәдә. Бу вазифаны бездә гомер-гомергә матур әдәбият башкарып килде. Ничәмә-ничә буын, әдәби әсәрләр, китаплар ярдәмендә тәрбияләнеп, үз асылын саклады, рухи нигезен ныгытты. Гомумән, китаптан башка камил шәхес формалаштыру мөмкин түгел. Әдәби китаплар яшь буынны ана телендә камил дәрәҗәдә сөйләшергә, укырга-язарга, образлы итеп фикерләргә өйрәтә һәм, иң мөһиме, милли үзаңны сакларга булыша. Шуңа күрәдер, матур әдәбият, язучылык эшчәнлеге элек-электән хөкүмәтнең дә, киң җәмәгатьчелекнең дә игътибар үзәгендә булып килде һәм килә. Без бүген әдәбият җәмгыятьнең рухи һәм әхлакый барометры икәнен һәрвакыт күз уңында тотып эш итәргә бурычлы. Матур әдәбият, чыккан китапларның сыйфаты һәм саны телнең дә, халыкның да яшәешен аермачык күрсәтеп тора.

Татарстан китап нәшрияты әдәбиятыбызга 100 елга якын хезмәт итеп килә, милләтебезне һәм ана телебезне саклый. Аның чишмә башында күренекле классик язучыбыз, әдәбият һәм тел галиме, җәмәгать һәм сәясәт-дәүләт эшлеклесе Галимҗан Ибраһимов тора. Бер гасыр вакыт эчендә бирედә меңәрләгән исемдәге китап дөнья күргән, нәшрият хезмәткәрләренең күбесе язучылар булган. Алар арасында Фатих Кәрим, Гомәр Бәширов, Байназар Әлменов, Мәхмүт Хөсәен, Шәүкәт Галиев, Марс Шабаев, Вакыйф Нуруллин, Харрас Әюп кебек күренекле әдипләр, рәссамнар бар. Бүгенге Татарстан китап нәшрияты – югары квалификацияле, үз эшен яхшы белеп, тырыш хезмәт куючы профессионаллар коллективы.

Именно поэтому литературная деятельность является объектом неустанного внимания государства и общественности, она служит своего рода барометром духовности и нравственности общества. Художественная литература, качество и количество издаваемой литературы являются показателями уровня жизни народа.

Вот уже около ста лет Татарское книжное издательство верно служит литературе, сохраняя нацию и ее язык. У его истоков стоял классик татарской литературы, литературовед и языковед, общественный и политический деятель Галимджан Ибрагимов. За вековую историю здесь увидели свет тысячи названий книг, большинство сотрудников издательства были писателями и поэтами. Среди них такие писатели и художники, как Фатих Карим, Гумер Баширов, Байназар Альменов, Махмут Хусаин, Шаукат Галиев, Марс Шабаев, Вакиф Нуруллин, Харрас Аюпов. Сегодня Татарское книжное издательство – это коллектив профессионалов высокого уровня, хорошо знающих свое дело.

Руководство республики уделяет много внимания развитию книжного дела, поддерживая Татарское книжное издательство в статусе государственного. Ежегодно издательством выпускается более 200 названий книг (включая учебную литературу), что также является показателем отношения государства к национальной литературе. Помимо Татарстана, Башкортостана, Чувашии и Саха (Якутии), в России нет подобных учреждений, издающих и распространяющих литературу, выплачивающих гонорар при государственной поддержке.

Татарское книжное издательство выпускает художественную и детскую литературу, исторические, научные, справочные издания, учебники, методические пособия, альбомы. Например, в 2015 году увидело свет 194 издания, а в 2016 – уже 226.

В 2015 году социально значимой литературы было издано 114 названий, в 2016 – 110, на 2017 год запланировано 117 названий. Остальное – это учебники, методические пособия, заказные издания.

С 2011 года 85% социально значимой литературы распространяется среди библиотек республики и по регионам компактного проживания татарского населения. Это продуманное

Республикабыз хөкүмәте китап бастыруга, Татарстан китап нәшриятын дәүләт нәшрияты буларак яшәтүгә һәм эшләтүгә аерым игътибар бирә, ел саен нәшрият (дәреслекләрне дә кертеп) 200дән артык исемдә китап бастырып чыгара икән, бу үзе үк дәүләтнең милли әдәбиятка булган мөнәсәбәтен күрсәтеп тора. Татарстан, Башкортстан, Чувашстан, Сахадан (Якутиядән) кала, бүген Россиядә дәүләт хисабына китап чыгару, аны тарату, авторларга гонорар түләү системасы бүтән юк.

Татарстан китап нәшрияты матур әдәбият һәм балалар китаплары; тарихи, фәнни, белешмә басмалар; дәреслекләр һәм методик әсбаплар; альбомнар бастырып чыгара. Мисал өчен, 2015 елда 194 исемдәге китап дөнья күрсә, 2016 елда без 226 исемдәге китап бастырып чыгардык.

2015 елда социаль әһәмияткә ия исемлек буенча 114, 2016 да – 110 исемдәге китап бастырсак, 2017 елда 117 исемдәге китап чыгарырга уйлыйбыз. Калганнары – дәреслекләр, методик әсбаплар, заказлы басмалар һ. б.

2011 елдан социаль әһәмияткә ия әдәбият исемлеге буенча чыккан китапларның 85%ы Республика китапханәләренә һәм татарлар күпләп яшәгән өлкәләргә җибәрелә. Бу – дөрес адым. Китап укучыга барып җитәргә тиеш.

Нәшриятның соңгы елларда ирешкән уңышлары шактый. Беренче чиратта, данлыклы Матбугат йортында, төзекләндерүдән соң, безнең фирма кибете ачылуны әйтеп узарга кирәк. Тантанада Республикабыз Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнеханов та катнашты. Бу – Казанда өченче кибетебез. Алдагы елда Шәриф Камал музее бинасында «Татар китабы йорты» ачылыр дип уйлыйбыз.

Нәшриятның сайты тулысынча яңартылып, «Татар әдәбияты үзәге» порталына әйләнде. Биредә беренче мәртәбә, басма китаплар белән беррәттән, электрон китаплар сатуга да юл ачылды, ягъни, тулы куәтенә интернет-кибет эшли башлады. Шулай ук онлайн-китапханәгә иркле рәвештә керү мөмкинлеге татар китабын түләүсез укуны дөнья күләмендә тәэмин итә. Татар теле һәм әдәбияты электрон дәреслекләреннән дә биредә бушка файдаланырга була.

Портал узган елның июленнән эшли башлады. Статистика буенча, бүгенге көнгә аңа 15 мең кулланучы кергән, 224 мең сумга 1500 китап сатып алынган. Монда нәшрият эшчәнлеге дә киң яктыртыла, яңа китаплар буенча оператив мәгълүмат та эленә. Порталны камилләштерү буенча эш дәвам итә.

Татарстан китап нәшрияты Россия һәм дөнья күләмендәге китап күргәзмәләрендә, ярминкәләрендә актив катнаша. Без чыгарган китаплар һәрвакыт югары бәяләнә, мактау кәгазьләренә, дипломнарга лаек була. Мисал өчен, 2015 елда Мәскәүнең

решение, так как книга должны доходить до своего потенциального читателя.

За последние годы в издательстве произошли качественные преобразования. Например, после ремонта в Доме печати был открыт фирменный книжный магазин. На торжественном мероприятии принял участие Президент Республики Татарстан Р. Н. Минниханов. Это третий магазин в Казани. Надеемся, что в скором будущем будет открыт «Татарский книжный дом» в здании музея Шарифа Камала.

Заметно преобразился сайт издательства, превратившись в портал татарской литературы. Наряду с книгами представлены и электронные издания, заработал интернет-магазин. Через бесплатную онлайн-библиотеку можно получить свободный доступ к татарским книгам. Здесь же можно воспользоваться электронными учебниками татарского языка и литературы.

Портал начал работать с июля прошлого года. По статистике, сегодня на нем зарегистрировано более 15 тыс. пользователей, приобретено 1500 изданий на сумму более 224 тыс. руб. На портале широко освещается деятельность издательства, предоставляется оперативная информация о новинках литературы.

Татарское книжное издательство принимает активное участие в российских и международных книжных выставках и ярмарках. Издания неоднократно становились их лауреатами и дипломантами. Среди таких изданий – альбом Нияза Халита и Наили Альменовой «Стили и формы татарской архитектуры Казани», «Шурале» Г. Тукая и др. Два года подряд издательство участвует в книжных выставках в столице Туркменистана Ашхабаде.

Недавно книги Равиля и Раиля Фахретдиновых «История татарского народа», «Моабитские тетради» М. Джалиля удостоились дипломов первой степени в конкурсе «Лучшие товары Республики Татарстан». Книга Г. Тукая «Шурале» стала лауреатом.

В рамках Федеральной целевой программы «Культура России» издательство получило 550 тыс. рублей, которые были направлены на издание таких книг, как «Сказки народов Татарстана», «Наследники Джалиля» и произведение А. Халима «Татарский солдат».

Совместно с Республиканским агентством по печати и массовым коммуникациям «Татмедиа» Татарское книжное издательство в рай-

Кызыл Мәйданында узган «Россия китаплары» фестивалендә Нияз Халит һәм Наилә Әлменова-Халитләрнең «Стили и формы татарской архитектуры Казани…» китап-альбомы, Габдулла Тукайның 15 телдә дөнья күргән «Шүрәле» әкият-поэмасы җиңү яулады. «Шүрәле» китабы Россия Федерациясе Президенты Владимир Путинга Татарстан Республикасының бүләге буларак тәкъдим ителде. 2016 елда безнең күргәзмә белән Россия Федерациясе Хөкүмәте башлыгы Дмитрий Медведев якыннан танышты, Муса Җәлилнең татар һәм рус телләрендә дөнья күргән «Моабит дәфтәрләре» китабы, «Татарстан Республикасы Милли китапханәсе» альбомы дипломнар белән бүләкләнде.

Ике ел рәттән Төрекмәнстанның башкаласы Ашһабад шәһәрендә узган китап күргәзмәсендә катнашып, Татарстан китап нәшрияты чыгарган «Татар китабы», «Татарча сөйләшик!», «Ак мамык» басмалары дипломнарга, рәхмәт хатларына лаек булды.

Күптән түгел Равил һәм Раил Фәхретдиновларның «История татарского народа» хезмәте, Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» «Татарстан Республикасының иң яхшы товарлары» конкурсында беренче дәрәҗә диплом белән бүләкләнде. Габдулла Тукайның «Шүрәле»се лауреат булды.

Нәшрият тарихында беренче мәртәбә «Культура России» Федераль максатчан программасы кысаларында без федераль бюджеттан 550 мең сум акча алуга ирештек. Шуның ярдәмендә «Татарстан халыклары әкиятләре», «Җәлил варисларына», Айдар Хәлимнең «Татар солдаты» китаплары дөнья күрде.

Татарстан китап нәшрияты, «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы белән берлектә, республикабыз районнарында «Китап бәйрәме» дигән проект башлап җибәргән иде. Без күренекле шагыйрьләрне, язучыларны, дәреслек авторларын үзебез белән районнарга алып чыгып, алар белән китап сөючеләрне очраштырабыз, китап күргәзмәсе һәм сату оештырабыз. Бу, беренчедән, укучыны яңа китаплар белән таныштыра, икенчедән, каләм ияләре белән, укытучыларга дәреслек авторлары белән якыннан аралашырга мөмкинлек бирә.

2016 ел Татарстан китап нәшрияты өчен бик тә нәтиҗәле һәм вакыйгаларга бай ел булды дип әйтәсем килә. Беренче нәүбәттә безнең эшчәнлегебез социаль әһәмияткә ия проектларны үстерүгә юнәлдерелде. Нәшрият, бөек шагыйребез Габдулла Тукайның тууына 130 ел тулу уңае белән шагыйрьнең әсәрләрен, аңа багышланган хезмәтләрне барлап, 13 исемдәге китап бастырып чыгарды. Алар барысы да 26 апрельгә – бәйрәм тантаналарына дөнья күреп өлгерде. Шулар арасыннан Татарстан Фәннәр академиясенең Галимҗан

онах республики реализует проект «Праздник книги». В рамках проекта проходят встречи с писателями, поэтами, авторами учебников, выставки литературы и продажа изданий.

2016 год для Татарского книжного издательства стал особенно плодотворным. Деятельность издательства была направлена на развитие социально значимых проектов. Так, к 130-летию Г. Тукая был подготовлен цикл замечательных изданий.

Начато издание трехтомника толкового словаря «Татарский мир» видного писателя, ученого Адлера Тимергалина. Это труд всей его жизни. Последний том планируется издать в 2018 году.

Достижением издательства с точки зрения содержания и оформления можно считать издание произведений Мифтахетдина Акмуллы, Мусы Джалиля, Сажиды Сулеймановой, Гарифа Ахунова, Габдрахмана Абсалямова, Рустема Кутуя, Хисама Камала, Мударриса Агляма, Рената Хариса, Радифа Гаташа, Разиля Валеева, Роберта Миннуллина, Ильдара Низамова, Набири Гиматдиновой, Галимьяна Гильманова, Ркаиля Зайдуллы, а также молодых авторов – Ленара Шаеха, Лианы Амирхановой, Альбины Абсалямовой, Алсу Нургатиной и др.

Издательство уделяет серьезное внимание изданию произведений татарской литературы в переводе на русский язык. В рамках серии «Мир татарской литературы» увидели свет сочинения Аяза Гилязова, Туфана Миннуллина, Хая Вахита, Аделя Кутуя, Фатиха Хусни. В этом году планируется издание произведений Амирхана Еники.

В благородном деле воспитания подрастающего поколения Татарское книжное издательство всегда выступало помощником учителей и родителей. Редакция детской и юношеской литературы и специальных проектов традиционно успешно занимается подготовкой литературы для данных категорий читателей.

За последние 10–15 лет в татарскую литературу пришло новое поколение авторов. Было издано около 20 изданий авторов моложе 35 лет. В этом году будет издано восемь сборников произведений молодых авторов.

В 2019 году Татарскому книжному издательству исполняется 100 лет. Издательство планирует достойно отметить эту знаменательную дату, прийти к ней с новыми достижениями.

Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты белән берлектә башкарылган зур хезмәт – Г. Тукай әсәрләре академик басмасының соңгы бишенче һәм алтынчы томнары чыгу безгә дә, китап сөючеләргә дә зур сөенеч алып килде. Зиннур Мансуров әзерләгән «Тукайча татар кодексы» татар, рус, инглиз телләрендә басылып, киң җәмәгатьчелек күңелен яулады. Бөек шагыйрьнең балалар өчен әсәрләре тупланган, дүрт китаптан торган һәм матур тартмага җыйналган басмасы сабыйларыбыз өчен дә, әти-әниләргә дә менә дигән бүләк булды. Бу – китап сөючеләрнең, укучыларның фикере.

Күренекле язучы, галим Адлер Тимергалинның өч томнан торган «Миллият сүзлеге»н нәшер итә башлау – иң зур уңышларыбызның берсе дип уйлыйм. Бу – язучының гомерлек хезмәте. Беренче том узган ел дөнья күрде, икенчесе быел, өченчесе 2018 елда басылып чыгачак.

Мифтахетдин Акмулла, Муса Җәлил, Сажидә Сөләйманова, Гариф Ахунов, Габдрахман Әпсәләмов, Рөстәм Кутуй, Хисам Камалов, Мөдәррис Әгъләм, бүгенге көн авторларыннан Ренат Харис, Рәдиф Гаташ, Разил Вәлиев, Роберт Миңнуллин, Илдар Низамов, Нәбирә Гыйматдинова, Галимҗан Гыйльманов, Ркаил Зәйдулла һәм башкаларның, яшьләрдән Ленар Шәех, Лиана Әмирханова, Альбина Әпсәләмова, Алсу Нургатиналарның китаплары эчтәлекләре ягыннан да, бизәлеше белән дә узган ел уңышы саналырга хаклы.

Нәшрият татар әдипләренең китапларын рус телендә чыгаруга да әһәмият бирә. «Мир татарской литературы» сериясе кысаларында Аяз Гыйләҗев, Туфан Миңнуллин, Хәй Вахит, Гадел Кутуй, Фатих Хөснинең китаплары басылды. Быел исә Әмирхан Еникинең әсәрләре дөнья күрәчәк.

Татарстан китап нәшрияты яшь буынны күркәм традицияләребез үрнәгендә тәрбияләүдә гаилә һәм мәктәпнең иң зур таянычы, ярдәмчесе булып торды һәм әлеге вазифаны бүген дә лаеклы рәвештә башкара. Бу эш белән бездә турыдан-туры балалар һәм яшүсмерләр әдәбияты, махсус проектлар редакциясе шөгыльләнә. Аның тарафыннан әзерләп чыгарылган китаплар турыдан-туры балаларыбыз кулына килеп керә.

Ун-унбиш елда татар әдәбиятына яңа көчләр, яшь алмаш килде. Алар тулы бер буын булып формалашты. Китаплары да гел басылып тора. Татарстан китап нәшриятында соңгы елларда 35 яшькә кадәрге авторларның егермеләп китабы дөнья күрде. Быел сигез яшь каләм иясенең мөстәкыйль җыентыклары басылачак.

2019 елда Татарстан китап нәшрияты оешуга 100 ел тула. Без әлеге тантананы зур әзерлек белән каршы алырга һәм билгеләп үтәргә уйлыйбыз.

**6 июня 2016 года в «Литературной газете» была опубликована статья Гузяль Эркаевой, ведущего библиотекаря Костенеевской сельской библиотеки Елабужского района Республики Татарстан, «Счастлив библиотекарь – счастлив читатель», в которой её автор делится опытом своей работы по привлечению читателей в библиотеку. Статья написана эмоционально, с болью за будущее нашей профессии… Предлагаем и Вам, наши дорогие читатели, присоединиться к нам и высказать своё мнение на эту животрепещущую тему…**



# СЧАСТЛИВ БИБЛИОТЕКАРЬ – СЧАСТЛИВ ЧИТАТЕЛЬ

Есть такие библиотекари, которые переживают, что книга уходит на второй план, библиотеки превращаются в досуговый центр. Честь и хвала им за это! Но сейчас одной книгой в библиотеку людей не привлечёшь.

Когда создавались библиотеки, не было Интернета, электронных книг, телевидения и радио. Книга была единственным источником информации. Сейчас на наши головы отовсюду поступает столько информации, только успевай её перерабатывать. А ещё бешеный ритм жизни делает своё дело, у людей просто не хватает времени на чтение книг. Как сказала героиня рассказа «Женский разговор» В. Распутина: «Самая жизнь гончей породы».

Недавно мне попалась в руки статья «Профессии, которых не станет уже через 20 лет». Футурологи назвали специальности, на которые, по их мнению, не стоит учиться: они станут не нужны. Были названы такие профессии, как бухгалтер, сметчик, стенографист, расшифровщик, турагент, менеджер по кредитам, провизор, архивариус, корректор и библиотекарь.

По моему мнению, будут жить библиотеки или нет, зависит от нас, библиотекарей. Мне кажется, что если библиотека станет удобной, заметной и нужной, то отпадёт сама мысль о закрытии библиотеки.

Однажды я сидела в библиотеке в гордом одиночестве – за целый день в библиотеку не пришёл ни один человек. Мне стало не по себе. Я решила сделать всё возможное и невозможное, чтобы привлечь как можно больше читателей в библиотеку.

Что я сделала в первую очередь? Объявила много разных конкурсов: «Лидер чтения», «Самый читающий класс», «Учитель – пропагандист книги» и другие. Затем прошлась по всем организациям, которые есть в нашем селе, и призвала работников этих учреждений к взаимовыгодному сотрудничеству. Провела родительское собрание в библиотеке, на котором привела весомые доказательства пользы чтения, рассказала об успешных читателях, которые много времени проводили в библиотеке. С большим размахом провела такие массовые мероприятия, как «Праздник книги», ток-шоу «Самая интересная девушка – читающая девушка» и другие. Активно заработали такие кружки и клубы в библиотеке, как «Театр книги», кукольный театр, клуб любителей авторской песни «Поющая душа», «Школа волшебников и изобретателей». Обо всём, что происходило в стенах библиотеки и вне её, я рассказывала в различных СМИ. Мне хотелось, чтобы слово «библиотека» звучало на

каждом углу. Свою работу строила, исходя из интересов сельских жителей, с целью выявления которых провела небольшие исследования, опросы, анкетирование.

У нас, библиотекарей, по сравнению с другими профессиями больше свободы, привилегий. Мы можем работать в самых разных направлениях, использовать разные формы и методы, нам сейчас не навязываются директивы «сверху». Считаю, что библиотекарь должен выбирать те направления, которые интересны и ему самому, так как то, что сделано с любовью, даёт ощутимый результат.

### МОЛОДЁЖЬ И ЧТЕНИЕ – ВОТ ЛУЧШЕЕ РЕШЕНИЕ!

Затем подросли мои дети, чтобы быть с ними ещё ближе, я перенаправила свою деятельность на работу с молодёжью. Я отправилась в город, в Управление по делам молодёжи и спорту. Руководству этого учреждения задала вопрос, какую они проводят работу с сельской молодёжью. Оказалось, что никакую. Я приехала со своей программой и призвала их провести несколько мероприятий совместно. Мы вместе провели КВН между деревнями и сёлами в нашем селе, шоу под названием «Бизнес и экономика», акцию «Брось курить!». Я никогда не забуду тот день, когда к нам приехала городская молодёжь со своей программой. Перед началом мероприятия ведущий сказал: «В этом зале находится наш друг, Гузяль Динамовна Эркаева». При этих словах весь зал встал, раздались громкие аплодисменты.

### ОТ ИГРУШКИ К КНИГЕ

Когда мои дети повзрослели и стали жить самостоятельной жизнью, я переключилась на формирование интереса к чтению у детей. Было время, когда многие коллекционировали игрушки из киндер-сюрпризов, и свою коллекцию я принесла в библиотеку. Глядя на меня, многие дети стали приносить свои. Когда мамы выбирали книги, просматривали периодику в библиотеке, их дети играли. Вскоре у нас появились железная дорога, конструкторы «Лего», мягкие игрушки, шахматы, шашки, пазлы. Дети после школы спешили в библиотеку. Они сразу принимались играть в разные игры, из деталей конструктора «Лего» у нас росли города, по которым ездили машинки. При этом не было хаоса, каждый был увлечён каким-нибудь делом, находились и те, кто любит читать в уединении. Глядя на таких детей, другие потихоньку переключались на книги, начинали делать домашнее задание. Многие, увидев в библиотеке большое количество ребят, называли её детским садом. Глупо требовать от детей, чтобы они постоянно читали. Они должны играть, отдыхать от учёбы. Наши дети шли в библиотеку с целью поиграть, а уходили всегда с книгой.

### МУЛЬТФИЛЬМЫ И КИНО

Мне не хватало техники для более плодотворной работы, я мечтала о мультимедийном проекторе. Тогда я стала участвовать в конкурсах, грантах. Выигрывала с лёгкостью, потому что рассказывала о своих новых программах. Сейчас библиотека хорошо технически оснащена. Я закачала на диски много разных познавательных мультфильмов, дети переключились на них. Затем дети стали приносить диски с художественными фильмами, многие из них сняты по книгам. Как детям нравится, когда я сажусь вместе с ними и смотрю фильм! А потом мы обсуждаем его, делаем выводы. Чтение не навязывается детям, я просто расставляю книги так, чтобы ребятишкам захотелось взять их в руки и прочитать.

### МАСТЕР-КЛАСС

Затем на моём жизненном пути стали попадаться люди, которые могли своими руками делать красивые вещи. Я попросила их научить своему мастерству моих читателей. Мастерицы приносили с собой книги с пошаговыми иллюстрированными инструкциями. Мои читатели научились многому: это и вышивка атласными лентами, и изонити, и квиллинг, и скрапбукинг, и лепка из пластилина, и оригами.

### БИБЛИОТЕКАРЬ БЕРЕЖЁТ ДЕНЬГИ И НЕРВЫ СЕЛЬСКИХ ЖИТЕЛЕЙ

Я хочу рассказать о том, как библиотека помогла не только сельской администрации, но и всему селу. Дело в том, что к нам в село стали приходить квитанции об оплате услуг ЖКХ, хотя никакие услуги нам не оказывались, причём платить надо было немаленькую сумму – от 500 до 1500 рублей каждый месяц. И многие сельчане как добросовестные граждане платили.Вооружившись законами, досконально изучив Жилищный и Гражданский кодексы, проконсультировавшись у специалистов, я во всём разобралась, подготовила разъяснения для населения и главы села и поехала в город, к директору ЖКХ. Оперируя статьями и законами, я привела ему неопровержимые доказательства многочисленных нарушений и убедила, что они незаконно взимают деньги. После этого квитанции от ЖКХ приходить перестали, все долги сельчан аннулировали. Стоит ли говорить, как мне были благодарны односельчане!

### СДЕЛАЙ ПРАВИЛЬНЫЙ ВЫБОР!

Говорят, что если счастлива мама, то счастлива и её семья. Перефразируя эту фразу, скажу: «Счастлив библиотекарь – счастлив и читатель». Я люблю свою работу, благодарна судьбе, подарившей мне такую замечательную профессию. И это чувствуют мои читатели, поэтому в библиотеке часто бывает многолюдно.

Проблема в том, что библиотекарей, которые живут своей работой, энтузиастов с развитой фантазией не так много. Каждый библиотекарь должен сделать для себя выбор.

Плыть по течению, ничего не предпринимать и не внедрять ничего нового. Но жизнь такая бывает скучной, рабочий день при таком ритме тянется бесконечно. Да и глупо при наших возможностях жить такой жизнью. У таких библиотекарей библиотека становится книгохранилищем.

Жить насыщенной, интересной жизнью, каждый день что-нибудь придумывать и воплощать в жизнь. И обязательно надо любить людей и свою работу, другим не место в библиотеке.

Какой путь выбираете вы, библиотекари?

В заключение хочу сказать, что, несмотря ни на что, книга всегда остаётся в цене, и это понимают молодые родители, которые стремятся дать своим детям хорошее образование, привлекают их к чтению. На Западе от электронных книг многие школы начали отказываться, так как электронные книги негативно влияют на здоровье. Так что ещё не всё потеряно! ■

**Гузяль ЭРКАЕВА,**
*ведущий библиотекарь Костенеевской сельской библиотеки Елабужского района Республики Татарстан.*
*(Литературная газета. – 2016. – 6 июня. – С. 10.)*

Татарстанның Алабуга районы Костенеево авылы китапханәчесе Гүзәл Эркаева күңел таләбе белән, китап язмышы, китапханәче һөнәренең киләчәге өчен борчылып язган мәкаләсендә җәмәгатьчелекне, бигрәк тә балаларны һәм яшүсмерләрне китап укуга күбрәк җәлеп итү серләрен ача, үз эш тәҗрибәсенең башкаларга да файдалы булачагына ышанып, тәпле киңәшләр бирә.

**Огромные окна библиотеки, с видом на парк, не закрыты ни шторами, ни жалюзи. Вечером освещенная библиотека привлекает прохожих, приглашая зайти и окунуться в мир книг и информации. На широких подоконниках разбросаны подушки, можно сесть и почитать прямо здесь, кашпо с искусственной зеленой травой как бы продолжают газоны парка. Такой предстает обновленная библиотека им.Тукая перед своими посетителями.**

# ЕСТЬ ТАКАЯ БИБЛИОТЕКА!

Торжественное открытие Центральной библиотеки города Нижнекамска и парка чтения и отдыха имени Тукая состоялось с участием Президента РТ Р.Н.Минниханова в августе 2015 года. По словам Президента, такое соседство тематического парка и библиотеки станет примером не только для Татарстана, но и для всей страны.

Открытие библиотеки нового формата, современного дизайна и содержания стало событием для всего города. Нижнекамцы семьями и дружескими компаниями приходили в библиотеку на экскурсии, знакомились с ее новым оформлением и наполнением.

Тукаевская библиотека сегодня не имеет традиционных отделов – абонемента и читального зала. В двух больших просторных залах в открытом доступе размещен весь книжный фонд, периодические издания.Вся литература, кроме самых ценных изданий, выдается на дом.В едином пространстве размещены и стеллажи с литературой и периодикой, и рабочие читательские места с компьютерами, и мягкие пуфы и кресла.

Широкие теплые подоконники библиотеки стали излюбленным местом молодежи, которая свободно располагается на подушках со своими телефонами и планшетами в руках, ведь в библиотеке есть свободная зона Wi-Fi.

В библиотеке выделены детская зона, зона литературного кафе с кофе-автоматом, творческая гостиная для занятий кружков и проведения мастер-классов. В конференц-зале библиотеки регулярно проводятся различные встречи, семинары, заседания, например, занятия литературного клуба «Селена» под руководством писателя Бориса Власова или заседания нового городского литературного объединения «Берега». На сцене в зале художественной литературы проходят встречи с местными и приехавшими из столиц писателями, интересными людьми. В творческой мастерской работают мастер-классы по обучению детей поделкам из соленого теста, а также технике декупаж и оригами. В зоне кафе и периодики собираются члены поэтических клубов «Әдәби җомга» и «Субботним вечером», читают стихи для присутствующих читателей.

В залах библиотеки установлены шесть компьютеров для пользователей, которые очень востребованы и детьми, и взрослыми. Молодые люди приходят в библиотеку, чтобы зайти в Интернет и соцсети со своих планшетов и телефонов. С 2015 года библиотека предлагает пользователям новую услугу – электронную библиотеку крупнейшей россий-

ской фирмы современных авторов ЛитРес, которая дает возможность выбора литературы на любой вкус, использование мобильных устройств для чтения книг, не выходя из дома. Для этого нужно только получить читательский билет в библиотеке и зарегистрироваться на сайте ЛитРес.



*Начальник управления культуры Г.М.Мубаракшина, председатель Госсовета РТ Ф.Х.Мухаметшин, директор библиотеки Г.Р.Арсланова*

Библиотечное обслуживание населения распространилось и за пределы библиотеки, оно вышло в соседний парк имени Тукая. Коллективом Центральной библиотеки внедрена новая форма работы – «Литературная среда»: еженедельно по средам библиотекари проводят в парках различные акции для детей и взрослых. С успехом распространилась литературная квест-игра. Квесты начинаются в библиотеке, затем участники для выполнения задания переходят в парк. В квестах задействованы литературные герои, ростовые куклы, скульптуры парка.

На Летней эстраде парка Центральной библиотекой организуются встречи с местными писателями и гостями из города Набережные Челны. Перед посетителями парка выступили Нурзия Мирхазова, Анжела Пильщикова, Раиля Каримова, члены клуба «Литературный четверг» библиотеки №3, члены литературно-молодежного клуба г.Нижнекамска, гости из Набережных Челнов – Разина Мухияр, Факиль Сафин и другие. В эти дни в парке выставляется «открытый микрофон», и все желающие могут прочитать свои стихи.

Осенью 2015 года, завершая Год литературы, в библиотеке прошел цикл встреч с писателями.

В поэтическом клубе «Субботним вечером» нижнекамские любители литературы собрались на презентацию коллективного сборника поэзии «Надеждою дышу», изданного региональным отделением фонда социального развития «Надежда». В сборник вошли произведения поэтов Казани, Набережных Челнов и Нижнекамска. Инициатором издания и составителем сборника стал молодой поэт Ильдар Сафин. Он рассказал о том, как создавался сборник, поблагодарил поэтов и писателей города за активное участие в работе над книгой и подарил каждому авторский экземпляр. Один экземпляр книги был подарен библиотеке. Выступили руководители литературного объединения «Данко» Д.Филиппов, литературной ассоциации «АМНТЧТМ» Р. Гатупов, а также их члены Н. Матвеев, Н. Бочкарева, О. Аблакотова, А. Пильщикова, М. Романов, В. Золов и другие. Поэты читали свои стихи, опубликованные в сборнике.

«Портреты и судьбы» – так называлась творческая встреча с членом Союза российских писателей Борисом Власовым, которая состоялась в конференц-зале Центральной библиотеки им.Тукая. Гость библиотеки рассказал о своих встречах с известными писателями Светланой Алексиевич (лауреатом Нобелевской премии по литературе 2015 года), Борисом Васильевым, Дарьей Донцовой, с которыми он познакомился будучи слушателем литературных курсов в Москве. Рассказ сопровождался виртуальной выставкой «О героях и судьбах». Первые рассказы Бориса Павловича были посвящены в основном производственным темам. Но при этом его называют дамским писателем и сказочником, так как его произведения всегда заканчиваются хорошо. Все его пять книг были изданы в Москве.

Завершение Года литературы в Нижнекамске ознаменовалось



*Посиделки в субботу вечером*



*Презентация книги «Нижнекамск – история в 50 лет»*

приездом в город актера и поэта Валентина Гафта. Камерная встреча в литературной гостиной собрала около ста человек – работников образования, культуры, представителей общественных организаций. Перед началом встречи Валентину Гафту предложили экскурсию по библиотеке, библиотекари прочитали для него стихотворение Габдуллы Тукая на татарском языке. «Изумительный язык», – восхитился он. На встрече с читателями, подготовленной коллективами ЦБ и филиала №3, Валентин Гафт о себе говорил мало – больше декламировал стихи. О детстве, о друзьях-актёрах, о смысле жизни, о судьбе, о театре… Собравшиеся не могли отпустить поэта без его знаменитых эпиграмм. Члены Литературного клуба Нижнекамска прочитали Валентину Гафту пару его стихотворений – автор остался доволен. А после встречи его ещё долго не отпускали – фотографировались, дарили цветы, брали автографы…

Встречи с российскими знаменитостями были продолжены и в 2016 году. 30 января в зале художественной литературы состоялась встреча с российским актером и сценаристом Никитой Высоцким. Он предстал перед читающей публикой Нижнекамска как сценарист, рассказав гостям встречи три истории с условными названиями «Ипподром», «Театр» и «Звезды». Возможно, когда-нибудь мы увидим фильмы, снятые по этим историям. Никита Высоцкий прочитал три своих любимых стихотворения – это были стихи А.Блока, Б.Пастернака и Н.Гумилева. В заключение гость ответил на вопросы участников встречи, в основном они касались фильма о Владимире Высоцком «Спасибо, что живой», автором сценария которого и является Никита Владимирович. На встречу были приглашены члены литературных объединений, журналисты, работники культуры, более 100 человек.

В течение 2016 года тематические встречи в библиотеке продолжились. В литературной гостиной с большим успехом прошел музыкальный вечер «Разноцветный джаз», посвященный 100-летию со дня рождения известного музыканта и дирижера Олега Лундстрема. В программе приняли участие Игорь Кириллов (гитара) и Иван Мещанинов (саксофон). Ведущая вечера познакомила зрителей с фрагментами биографии маэстро, в частности, с казанским периодом творчества Олега Лундстрема. К вечеру были подготовлены презентация и выставка литературы «В легком жанре».

14 февраля 2016 года всенародно любимой певице Анне Герман исполнилось бы 80 лет. В литературной гостиной с огромным успехом прошел вечер вокальной музыки «Свет звезды», посвященный юбилею незабываемой артистки. В программе вечера приняла участие популярная нижнекамская певица Оксана Ялтанская. Гости вечера с огромным вниманием слушали рассказ о нелегкой судьбе польской певицы, прожившей не долгую, но такую блистательную жизнь.

2016 год – год 50-летия города Нижнекамска. В городе были успешно реализованы несколько крупных проектов – открытие городского парка «Семья», обновленной набережной, издание нескольких книг и альбомов. Презентации двух новых книг о Нижнекамске состоялись в Центральной библиотеке и стали заметным событием в культурной жизни города. В апреле Центральная библиотека им. Тукая принимала гостей – героев книги Г.С. Сабирова «Знали – город будет» – первостроителей города. На презентацию издания собрались строители, педагоги, медики, работники торговли, образования и культуры, социальной сферы, руководители предприятий – все, кто стоял у истоков города. Книга Галимзяна Сабирова стала первой, вышедшей в свет в год 50-летия Нижнекамска, и интерес к ней был огромен.

В конце сентября состоялась презентация уникального энциклопедического издания «Нижнекамск – история в 50 лет» и фотоальбома к юбилею города. «Наша книга не менее значима для города, чем набережная или городской парк», – так обозначила важность издания заместитель главы администрации Эльвира Долотказина. Праздничным вечером в библиотеке завершилась кропотливая работа редакционных команд, которые в течение всего года трудились над созданием уникальной книги. Все, кто принимал участие в этой работе, предоставлял материалы, фотографии, проявил личное участие, были приглашены на презентацию и получили экземпляр книги в подарок, среди них и несколько библиотечных работников.

Прошел уже год работы библиотеки в новом формате, этот год показал, что число пользователей и посещений библиотеки возросло в два раза и продолжает удерживаться на этом уровне. Это подтверждает предположение, что уровень комфортности и качества предоставляемых услуг позволяет библиотеке занять свое достойное место в городском пространстве. ■

**Елена ВАСИЛЕНКО,**
*главный библиотекарь методического отдела МБУ «ЦБС г.Нижнекамска им. Г.Тукая»*

Түбән Кама шәһәрендәге үзәк китапханә «икенче яшьлеген» кичерә. Бөек шагыйребез Габдулла Тукай исемен горур йөртүче әлеге китапханәдә тулы төзекләндерү үткәрделәр. Үзенчәлекле форматта, заманча дизайн һәм яңача эчтәлек белән үзгәртеп корылган «Китап йорты»ның ачылышы шәһәр һәм республикабыз өчен генә түгел, бөтен Россия өчен зур вакыйга булды. Журналыбыз укучыларын биредәге үзгәрешләр һәм яңалыклар белән таныштырабыз.

# ТУКАЙ КИТАПХАНӘСЕНЕҢ ХӘЗЕРГЕ КӨНЕ



Ачык һавада кино карау

**1972 елның декабрь аенда ачылып, шул еллар өчен заманча төзелгән биш катлы йортның беренче катында зур мәйдан биләгән Габдулла Тукай исемендәге үзәк китапханә үзенең беренче укучыларына хезмәт күрсәтә башлаганнан бирле 44 ел узды.**

Шул елларда китапханә бинасы өч мәртәбә зур үзгәрешләр кичерде. Беренчесе, узган гасырның сиксәненче елларында булып, китапханәгә яңа керү урыны төзелде һәм яңа дизайнлы бүлекләр барлыкка килде. Икенчесе туксанынчы елларда китапханә янәшәсендә урнашкан саклык банкы яңа махсус бинага күчү сәбәпле, бушаган мәйданы Тукай китапханәсенә бүләк итеп бирелде. Бинаның икенче катында танылган рәссам, Тукай премиясе лауреаты Әхсән Фәтхетдиновның күргәзмәләр залы ачылды һәм шунда ук китапханәнең сәнгать бүлеге күчте.

Һәм өченчесе. 2015 елның гыйнвар аенда китапханәнең гамәлгә яраклы барча җиһазын филиалларга таратып, китапларын Кол Гали исемендәге китапханәгә вакытлыча күчереп бетергәннән соң, капиталь ремонт башланды. Зур тизлек, тырышлык белән һәм, иң мөһиме, шәһәр мэры Айдар Метшинның даими күзәтчелегендә, ремонт эшләренең беренче өлеше август аенда тәгәлләнде.

14 августта, Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнеханов катнашында, тантаналы рәвештә, Г.Тукай исемендәге үзәк китапханә яңа форматта үз ишекләрен ачты һәм шуннан соңгы берничә ай дәвамында түбәнкамалыларның яраткан урынына әйләнде.

Матур әдәбият һәм тармак әдәбияты заллары, Әдәби кафе, конференц-зал, иҗатханә һәм, иң көтелмәгәне, китап фондларын ябык рәвештә саклау бүлмәләре булмыйча, бар нәрсәнең дә ачык, күз алдында торуы – болар халык һәм без, китапханәчеләр тарафыннан искитәрлек яңалык булarak кабул ителде. Китапханәбез – Россиядәге шушындый төр китапханәләрнең дүртенчесе. Мәскәүдә, Петербургта, Владивостокта мондый китапханәләр бар. Г. Тукай исемендәге китапханәнең, аның янәшәсендә Тукай исемендәге уку һәм ял паркының ачылуын Россиядәге «Әдәбият елы» барышында башкарылган



*Әдәбият елын тәмаулау тантанасында мэр урынбасары Э.Р.Долотказина (уңнан беренче) китапханәчеләрне тәбрикли*

икенче зур вакыйга диләр (беренчесе – Мәскәүдәге Кызыл мәйданда үткән китап ярминкәсе). Парк белән китапханәнең махсус символикасы булдырылды һәм «Укы паркта, ял ит китапханәдә» дигән әйтем барлыкка килде. Ул гына да түгел, Татарстанда игълан ителгән «Парклар елы»ның нәтиҗәсе билгеләнгәндә Түбән Кама шәһәрендәге Тукай китапханәсе һәм Тукай уку һәм ял паркы елның иң зур ачышы дип табылды!

Әйтергә кирәк, хакимият башлыгыбыз Айдар Рәис улы Метшин әлеге үзгәреш белән генә чикләнмәде. Үзәк китапханә бинасының махсус укучылар өчен генә булырга тиешлеген белдереп, китапханәнең идарәсен, методик, китап туплау һәм эшкәртү бүлекләрен башка бинага күчерергә карар чыгарды. Әлеге карар инде тормышка ашты: бу бүлекләр 2016 елның март аеннан бирле Төзүчеләр урамындагы 11 В йортта капиталь ремонт үткәрелгән, 7 нче балалар китапханәсе бинасында үз вазыйфаларын дәвам иттеләр. Үзәк китапханәнең бушаган мәйданын заманча, кечкенәләрнең, яшүсмерләрнең игътибарын җәлеп итәрлек рәвештә үзгәртеп кору һәм балалар филиалын шунда күчерү алдагы ел планында тора.

Китапханәләр системасы директоры Гөлназ Рәмзил кызы Арсланова, укучыларга хезмәт күрсәтү бүлеге мөдире Әнфисә Зиннур кызы Фәйзетдинова җитәкчелегендә Тукай исемендәге үзәк китапханәнең иҗади, креатив коллективы, китапханәнең барлык мөмкинлекләрен кулланып, шәһәр халкына хезмәт күрсәтә. Даими эш юнәлешенә әверелеп барган яңа башлангычларның кайберләрен генә әйтеп китү дә эшчәнлекнең ни дәрәҗәдә югары һәм сыйфатлы барышын билгели, шәһәрдәшләрдә басма китапка карата кызыксыну уятуны зур дәрәҗәгә күтәрү дәлиле булып тора.

Китапханәдә ремонт барышында халыкны бер көнгә дә китапсыз калдырмадык. Буккроссинг юнәлеше киң җәелеп китте. «Макдоналдс», «Арка астындагы сәүдә» комплексы яннарында китап киштәсе һәм үзенчәлекле «китап йорты» урнашты. Үзәк китапханә һәм 37 нче филиал хезмәткәрләре аларны китаплар белән даими тулыландырып тордылар. Халыкны да бу күркәм һәм файдалы китап алышуга чакырып,«Өйдәге укылган китапларны – китапханәләргә!» дип, телевидениедән сюжетлар, язмача һәм телдән игъланнар бирелде. Түбәнкамылыларның бу акцияне хуплап китапханәгә агылуы бер елга сузылды.



*Мәдәният университеты студентлары һәм мөгаллимнәре*




*Мөхәммәт Шәйхи китабын презентацияләүдән соң*

Әдәбият елы, Габдулла Тукайның тууына 130 ел тулу, Түбән Каманың 50 еллык юбилее яңа иҗади бәйләнешләргә этәрде. «Таттелеком», «Медтехника» оешмалары әдәби чараларны Тукай китапханәсе залларында уздыруны кулай күрде. Ә.З. Фәйзетдинова һәм Р.Г. Камбиеваны шәһәр медицина учреждениеләре баш табибларының җыелышларында катнашырга чакыра башладылар. Китапханәдә һәм шифаханәдә эшләүчеләр – бер максат кешеләре. Врачлар авыру кешенең тәнен дәваласа, китапханәчеләр китаплар белән кешенең җанын дәвалый. Бәйрәм алды көннәрендә әдәби әсәрләр үрнәгендә тәбрикләүләр, баш врачлар үтенече буенча табибшагыйрьләр белән очрашу кичәләре Тукай китапханәсе эшенең күркәм тәҗрибәсе булып шәһәребез тарихында калыр.

Язын, җәен, көзен көннәр җылы торган чакта Уку һәм ял паркының «Җәйге эстрада» сәхнәсендә «Әдәби чәршәмбе = Литературная среда» чаралары үткәрелә. Циклның аталышына килгәндә, түбәндәгене әйтү урынлы булыр. 2015 ел – Әдәбият һәм Парклар елы буларак билгеләнеп үтте. Китапның, укуның, китапханәнең кеше тормышында зур урын биләгәнен күрсәтеп, аны яшәү мохите биеклегенә күтәрү максатыннан бирелгән исем иде бу. Исем җисеменә бик тә туры килде! Сәхнәдән җирле, Казан, Чаллы шәһәрләреннән килгән язучылар, Түбән Каманың танылган һәм киң җәмәгатьчелеккә бигүк билгеле булмаган иҗатчылары, мәдәният хезмәткәрләре, китапханәләрнең даими укучылары, төрле оешмаларның вәкилләре чыгыш ясарга өлгерде. Очрашуларның истәлеге булып газета битләрендә мәкаләләр, телевидениедән күрсәтелгән сюжетлар, фотолар, шигырьләр кала. Мәсәлән, тугыз әдәби китап авторы Рәзинә Хәйбрахман кызы Мөхияр, үзе яши, иҗат итә торган Чаллы шәһәренә кайткач, бездә узган очрашу тәэсирләрен яңартып, түбәндәге шигъри юлларын язган:

*Сентябрьдә яфракларның*
*Иң купшысы, иң яктысы.*
*Аллы-гөлле гөлләмәләр...*
*Җанга күчә ут-ялкыны.*

*Түбән Кама. Тукай паркы...*
*Яше-карты шигырь тыңлый.*
*Күктән яуган яңгыр да бит*
*Шигырьгә көй салып җырлый.*

*Яңгыр ява тыпырдатып,*
*Йөрәкләрдә наз уятып.*
*Яңгыр-шигырь бергә ява,*
*Күңел-җанны кузгатып.*

Тукай уку һәм ял итү паркының «Җәйге сәхнә»сендә, һичшиксез, Кино елы да үз урынын алды. 19 июньдә шәһәр тарихында беренче тапкыр ачык һавада «Большая перемена» фильмын карап, аның буенча фикер алышу үтте. Октябрь аеның матур кичләрендә дә паркта күмәкләшеп фильмнар карау дәвам итте. Ә китапханәдәге «Киноклуб» уты-



*Әдәби трамвай*

рышларында совет һәм бүгенге чор, чит ил әдәбиятына нигезләнеп төшерелгән фильмнарны карау мөмкинлеге булды.

Өлкәннәрнең «Яшьлегем чишмәләре», «Посиделки на заваленке» ял итү һәм аралашу клубларына йөрүчеләр, һәр чәршәмбедә «Җәйге сәхнә»тирәли истәлек-хатирәләргә бирелеп, мөһим вакыйгаларга һәм юбилей даталарына карата әңгәмәләр тыңлап, укып, җырлап файдалы һәм кызык итеп вакытларын үткәрәләр. Салкын һәм яңгырлы көннәрдә китапханә бинасында очрашалар.

Әдәбият елында Тукай исемендәге үзәк китапханәнең конференц-залында яшь каләм тибрәтүчеләрнең «Каурый каләм» (татар телендә), «Селена» (рус телендә) клуб утырышлары узды. Монда ук «Интеграция. Движение – это жизнь» инвалидлар оешмасы әгъзалары өчен «В кругу друзей = Дуслар арасында» дигән клуб атнага ике тапкыр үз эшчәнлеген оештырып төрледән-төрле әңгәмәләр, уен-викториналар, мастер-класслар үткәрә.

«Әдәби җомга» һәм «В субботу вечером» циклы Әдәби кафеда уза. Җирле язучылар үз укучылары белән һәр атна саен күзгә-күз очрашалар. Бу укучыга да, язучыга да, рухи дөньяларын баетырга мөмкинлек бирә.

«Җәй – китап белән», «Дәваханәдә китап», «Сәяхәтче китап», «Ел әйләнә шәһәр буйлап», «Әдәби трамвай» һәм башка күп цикл-проектлар уңышлы тормышка ашып бара.

*Элек анда юкка гына алпавыт имениеләре, монастырь, Апанаевның һәм Глазковның (халык мәгарифе министрлыгыннан) дачалары, бакчалары булмаган! Безнең авыл җирлегендә, аның болын, сулары буенда менә дигән ял йорты, балык күлләре ясап була (элек ике балык күле бар иде). Халык өчен тагын башка эш тә табып булыр иде: ферма, нинди булса да остаханә һ. б. Мин бу турыда сезнең җитәкчеләр белән сөйләштем, элемтәгә кердем. Берсе дә каршы*

*түгел. Кемдер бу эшкә алынырга һәм аны башкарып чыгарырга тиеш. Мин халык белән сөйләшү өчен (кирәк булса) бүген үк авылга кайтып килә алам. Бәлки августта шул мәсьәлә буенча кайтыргамы? Бу турыда райкомның икенче секретаре Зөфәр Шәйхетдинов белән сөйләшегез әле. Ни өчендер аннан хат килмәде. Шунда Шытсуга да кереп чыгар идек, безнең авылның табигате, матурлыгы белән дә танышырбыз, вакыт күбрәк булса, «Саба» совхозы турында да очеркка материал тупларга мөмкинлек булыр иде. Бәлки ул очеркны икебез бергә хәзерләп язар идек?*

*Менә ни хәтле сораулар, тәкъдимнәр. Сездән беренче үтенеч – бу турыда Зөфәр белән килешеп, миңа тизрәк хәбәр итүегезне сорыйм. Ашыгуның сәбәбе – мин 29 августтан Кисловодскига китәм, аннан кайткач Мәскәүгә – октябрьдә Бөтенсоюз күләмендәге фәнни конференция була, аннан Дубулты дигән Иҗат йортына – кыскасы, Казанда сирәк булачакмын. Көз һәм кыш авылга кайту уңайсыз.*

*Сезгә тагын зур рәхмәтләр, иң изге теләкләр белән олы уңышлар, көтелмәгән сөенечләр теләп (Сез миңа шундый көтелмәгән сөенеч ясадыгыз).*

Әбрар.
4 август, 1986.

***Хөрмәтле Тәлгат туган!***

*Халкыбызның теле һәм килеп чыгышы турында рус телендә язган мәкаләмне җибәрәм. Кирәк тапсагыз, «Җиңү байрагы»нда («Знамя Победы»да) басуыгызны сорар идем.*

*16 мартта Киевка китәм. Анда оешкан Татар җәмгыяте чакыруы буенча очрашуга барам. Соңгы китап чыккач («Прототюрки и индейцы Америки. По следам одной гипотезы»), бик күп җирләргә чакыра башладылар. Вакыт юк, шуның өстенә сәламәтлек әйбәт түгел. Саба урта мәктәбенә дә кайтасы бар.*

*Ул китап-хезмәт татарча да хәзерләнә. Бер җыентыкка кертеләчәк, апрель-майда дөнья күрәчәк.*

*Тагын бер илдән конференциягә чакыралар.*

*Сезгә чын күңелдән ихтирам белән, Саба якларын сагынып:*

Әбрар.
8 март, 1989 ел.

**P.S.** Сезгә «Суверенитет– не предмет торговли» дигән мәкаләмне җибәрәм. Бу әйбер Татар радиосы аша халыкка җиткерелде. Аннан район газетасының исемен дә үзгәртергә кирәк. Нинди «Җиңү байрагы» ул? Сталинизм җиңүеме? Бу исем – нонсенс. Тотыгыз да «Саба ягы», йә «Саба җиле», «Сабакул», «Байлар Сабасы»… менә шуларга охшаш исем табыгыз да кушыгыз...

***Кадерле Тәлгат туган!***

*Миңа бәйрәм алып килгән хатыгызны, хат эчендә «Җиңү байрагы»ның ике санын алдым. Инде аны рәсемем белән дә басып чыгару бәйрәм өстенә бәйрәм кебек булды.*

*Сабага күңел гел тарта. Менә шушы кыска гына вакытка кайтып, якташларны күреп китү, аларның мине онытмаулары яшәргә, эшләргә көч бирә булса кирәк. Сабадан кайткач Мәхмүт Нигьмәтҗановны күргән идем, ул бит Олы Арташтан, билгеле музыка белгече (беләсездер дип уйлыйм) – белгән булсам, мин дә кайткан булыр идем, диде.*

*Быел яңадан чит илгә барырга җыенабыз. Бер Халыкара конгресска чакыру килде, шуңа документлар әзерләп йөрибез.*

*Эш күп, хәзер барысына да җитешеп булмый. Ә планнар зур. Минем хәзер төп теләгем – революциягә хәтле чыккан бай татар китабы репертуарының тулы, фәнни, аннотацияле каталогын төзү. Быел бер кеше бирәләр, киләчәктә аерым группа төзеп, шул эшне юлга салырга иде. Революциягә хәтле 14 меңгә якын китап чыккан – татар китабы – менә шуларның фәнни тасвирламасын төзеп, халыкка җиткерә алсак, күп нәрсәләрнең кире кайтуы җиңеләер иде. Ул хезмәт минем исәпләвем буенча бер 15 зур томнардан торачак. Аны төзү буенча Финляндия, Төркия, Австриягә дә фәнни командировкалар күздә тотыла. Бу илләрдә дә шактый татар китаплары тупланган. Әгәр үзгәреш заманнары мин яшьрәк вакытта килсә, бу эшне активырак башкара алган булыр идем дә бит.*

*Тәлгат туган, Сезгә кабат рәхмәт белән иң изге теләкләрдә калам, яңа уңышлар, сөенечләр теләп*

Әбрар.
29 апрель, 1989.

**P.S.** Сезгә безнең филиал газетасының бер номерын җибәрәм, Овруцкий мәкаләсенә игътибар итегез.

***Хөрмәтле Тәлгат туган!***

*Сезнең карамакка Һәнүз Мәхмүтов дигән безнең Институт галименең информациясен җибәрәм. Үзем уңайсызланам да, чөнки анда сүз минем турыда бара. Бу инде бик үк килешеп бетми дә кебек. Чөнки үзеңне үзең пропагандалау сыман килеп чыга.*

*Бар да Сезнең карамакта. Бассагыз да рәхмәт, инде ярамый дип басмыйсыз икән, аңа да бернинди үпкәм булмас. Мәсьәләне үзегез хәл итәрсез.*

*Үзем турында бер-ике сүз. Әле генә Ленинградта булып кайттым, Анна Ахматованың улы – минем якын дустым профессор Лев Николаевич Гумилев чакырган иде. Анда булдым. Аның турында бер хезмәт төгәлләп бетердем, шәт, тиздән басылыр дигән өметтә. Профессор якташыбыз Яхъя Абдуллин һәм минем чакыру буенча Америкадан Рифат Тәби, Надир Дәүләт исемле ике татар галиме килә, шуларны каршы алуга*

*хәзерлек белән дә бик мәшгуль. Шулай ук «Идел буе татарлары» дигән монография язган Азадә-Гайшә Рорлих ханым – профессор да килә. Аның китабы турында үткән ел «Казан утлары» журналының 5-нче яки 6-нчы саннарында язып та чыккан идем. Аларны каршы алу, урнаштыру һәм татарлар, аларның мәдәнияте, Казан һәм аның кешеләре белән таныштыру буенча да эшләр җитәрлек булачак.*

*«Идел»дә (5 һәм 6 саннарында) Ерак Көнчыгыштагы илләрдә яшәгән милләттәшләребезнең язмышы буенча минем язмалар басылачак, бәлки кызыксынырсыз. Миннән Зөфәр Шәйхетдиновка сәлам әйтегез, газета редакциясендә мине белүчеләргә дә миннән сәлам тапшырыгыз.*

*Бүген-иртәгә «Аваз» газетасында минем Гумилевта булуым уңае белән кечкенә информация һәм аның бер мәкаләсе басылачак, рәсемен дә алып кайткан идем, кертерләрдер дип торам.*

*Борчуым өчен гафу итегез, чын күңелдән иң изге теләкләр теләп, якташыгыз, дустыгыз*

Әбрар.
16 май, 1990.

***Хөрмәтле Тәлгат туган!***

*«Җиңү байрагы»ның ике данәсен җибәргәнсез: Һ. Мәхмүтов мәкаләсен басуыгыз һәм ул санны җибәрүегез – ихтирам һәм изгелегегез өчен зур рәхмәт. Сабада минем хәзер ике генә якын кешем бар: Сез һәм Зөфәр Шәйхетдинов. Районнан чыгып киткәнгә кырык елдан артык вакыт узып китте. Элекке җепләр өзелде: кем мәңгелеккә китте, кем кая таралды. Мине Саба белән менә сез икегез бәйләп торасыз, монысы зур бәхет аның.*

*Һәнүз отпускада, ул кайткач, аңа газетаның бер санын тапшырырмын. Аның Сезнең дустыгыз Мөҗәһит Шәйхетдинов белән бергә укыганлыгын да белешермен, Һәнүз әле күптән түгел Кәрим Тинчурин турында бер җыентык әзерләп, нәшриятка тапшырды. Ул – бик тырыш, эшчән, намуслы егет, булган кеше, чын галим.*



Т.Нәҗмиев Кәримуллин укуларында. 2012 ел

*Сез Питрау сабан туена чакырып язгансыз хатыгызда. Ул вакытта бу бәйрәмне мин беренче күрдем, бик ошаган иде. Тик бу юлы кайта алмадым. Шәт, исән-сау булсак, киләсе елга дип калдырыйк.*

*Җәйнең шактый өлеше чит ил кунаклары белән мәшгуль булып үтте. Июньдә Америкадан өч татар профессоры килде: алар белән мин Америкада танышкан идем. Кунаклар безнең чакыру буенча килделәр. Берсе – Надир Дәүләт исемлесе – миндә, Рифат Тәби – Яхъя Абдуллинда, Азадә-Гайшә Рорлих Мирфатыйх Зәкиевтә торды. Алар архивларда һәм китапханәләрдә эшләделәр. Аларны галимнәр, журналистлар, язучылар белән дә очраштырдык, студентлар белән дә күрештеләр. Чаллы, Түбән Кама, Болгар-Йорт җирләрен дә күрсәттек. Бик разый булып киттеләр. Надир Дәүләт бөтендөнья төрки халыклар тарихы буенча эшли, шул исәптән татар тарихына да зур игътибар итә. Азадә-Гайшә ханым хәзер күренекле татар хатын-кызлары турында монография яза, киләчәктә татар сәүдәгәрләре һәм аларның халык мәгарифенә керткән өлеше турында эшләргә җыена. Ул – Көньяк Калифорния университетында профессор. Аннан «Ватан» җәмгыяте чакыруы буенча Япония, Австралия, Германия, Төркия, Финляндиядән татарлар килде. Ул җәмгыятьнең бер комиссиясе рәисе буларак, миңа да алар белән бергә эшлисе булды. Айга якын вакыт шулар белән үтте. Хәзер үзем бер 15-20 көнгә ялга чыктым, бакчада бераз эшләгән булып йөрим шунда. Август ахырында путевка булмасмы дип көтәм, санаторийга, аяк авырта, дәваланасы бар.*

*Әйе, Төркиядән бер төрек профессоры булып китте. Ул минем «Татары: этнос и этноним» дигән әйберне төрек теленә тәрҗемә иткән, шуны басарга дип рөхсәт сорады. Киләсе елга Төркиядә (Анкарада) үткәреләчәк фәнни конгресска чакырды.*

*Эшлисе килгән нәрсәләр күп-күбен дә, тик бик эшлисе килеп тормый. Шулай да әзрәк селкенәм инде шунда. Сәламәтлек җитми, шул тота, ә әйтәсе сүзләр күп.*

*Ярый, Тәлгат дус, шуның белән түгәрәклим. Миннән Зөфәргә күп итеп сәлам әйтегез. Райкомда Ногманов дигән бер егет эшли иде, аның әнисе белән бергә укыдык, аңа да сәлам әйтегез. «Саба» совхозы директорына да, очраша калсагыз.*

*Игътибарыгыз, хатыгыз, газета өчен тагын рәхмәт белән, изге теләкләр теләп калучы*

Әбрар.
20 июль, 1990.

***Тәлгат дус!***

*Сезнең 1 августта язган хатыгызны алдым, анда Сез «Саба районының 60 еллыгын билгеләп үтәргә җыенабыз», шул уңай белән үзегезнең котлау сүзегезне яисә шул вакыйга белән бәйле берәр язма җибәрүне сорагансыз.*

*Сүз Сабаны административ үзәк итеп билгеләү турында барамы? Мин бу турыда беренче мәртәбә ишетәм. Элек ул як ничек аталган, кемгә караган? Волостьмы, кантонмы булган? Минем Чәбия-Чүрчи авылы элек Казан губернасының Мамадыш өязе Әбде волостена караган. 1920 нче еллар башында Сатыш волосте да булган кебек. Күрәсез, мин бу 60 еллык уңае белән аңа бәйле берни белмим, димәк, яза да алмыйм.*

*Котлау дигәч, нәрсә әйтергә дә белмим диярлек. Бу 60 ел Саба районы кешеләренә нәрсә алып килде? Гомумән, сталинизм заманы, аннан брежневщина елларына караган бу 60 ел эчендә мактанырлык нәрсә булды икән? Нинди котлау сүзләре язарга соң?*

*Бердәнбер шулай дип язарга мөмкиндер:*

*«Якташларымны Саба районы оештырылуга 60 ел тулу уңае белән чын күңелдән котлыйм. Киләчәктә районның икътисады, милли мәдәният ягыннан Татарстан Республикасының (ә ул һичшиксез тулы хокуклы мөстәкыйль дәүләт булыр) мактаулы төбәге булуын телим.*

*Сталинчылар, үз ялагайларыбыз җимергән мәчетләр торгызылыр, халыкка әдәп, әхлак нурлары сибелер, корытылган чишмә, инешелгаларыбызның сулары мулланыр, сукаланган яшел болыннарыбызда шайтан таягы урынына мул үлән-чәчәкләр гөрләп үсә башлар, җимерелгән күперләребез яңадан эшләнер, кыр-басуларны машиналар таптап юллар салып йөрүгә чик куелыр, урман-кырларыбызны талау урынына, аларны акыллы файдалана башларбыз. Мәктәпләребездә элеккечә Тукай теле сөйләшер, балаларыбыз Альберт та, Роберт та түгел, яңадан Рөстәм вә Рәшитләшер, а Фаялаша, Маялаша, Раялаша башлаган кызларыбыз ата-аналары биргән изге исемнәренең кадерен белә башларлар иде, диясе килә киләчәктә.*

*Кайчан Өчнарат «Три сосны», Ике басу Арташ «Два поля Арташ», Байлар Сабасы «Богатые Сабы»лар булып яшәүдән туктап, үзләренең чын исемнәре белән йөртелә башлар, кадерле сабалылар, бу турыда да уйларга кирәк юбилей көннәрендә.*

*Бу 60 ел эчендә «матур тормышта» яшәгән Саба районының күпме әзмәвер кебек батыр егетләре туган йортларын ташлап ерак Шпецбирген атавы, Донбасс, Кузбасс шахталарына кузгалмады да, күпмеләре Карелия, Себер якларына урман кисүгә юл алмады, китте, югалды, кире кайтмады. 60 еллыкны үткәргәндә менә боларны да онытмыйк. Саба якларының мең еллардан артык гыйбрәтле тарихы булуын да, аның Болгар дәүләте чорында ук даны зур төбәк икәнен дә күңелдән чыгармыйк. Ш. Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар» китабында Саба якларындагы даны ерак Көнчыгыш илләренә яхшы билгеле булган галимнәр искә алынган. Безнең төбәктә даны киң таралган күпме мәдрәсәләр эшләп торган, ә Сатыш мәдрәсәсенә нинди генә шәрык мөселман илләреннән укырга шәкертләр килмәгән? Безнең төбәк кешеләре эшкә дә, һөнәргә дә, гыйлемгә дә оста булганнар. Оренбург якларына барып бистәләр салганнар, Урта Азия, Кытай, Һиндстан, гарәпләр белән сәүдә итканнар, чит илләргә йөргәннәр. Истанбул, Каһирә уку йортларында белем алучылар да шактый булган (минем үземнең бабам Гата Ихсанов Истанбул университетында гыйлем алган, Мөхетдин Корбангалиев белән Ике басу Арташ, Чәбия-Чүрчи, Язлы Арташ авылларында земство хисабына татар дөньяви мәктәпләре оештыруда актив катнашкан), Саба ягыннан чыккан кешеләр арасында Россиянең чит илләрдә илче булып йөргән затлар да билгеле...*

*Болар әле өстә яткан фактлар гына. Саба районына 60 ел тулуны билгеләп үткәндә аның тарихын өйрәнүне дә киләчәктә эш планнарына кертү кирәктер, аерым авыл тарихын чагылдырган авыл музейлары да бар, ә безнең хәтта аерым бинада район музеебыз да юк бит. Монысын да онытмыйк, шушы юбилей көннәрендә.*

*Туган авыл, туган як – һәркем өчен иң изге, иң кадерле, иң газиз хис. Мең еллык тарихы булган Саба төбәгенең киләчәге, аның милли теле, милли моңы тагын да меңләгән гасырлар дәвам итүен кайсыбыз гына теләми, ә бу нәрсә бүгенге эшебез, гамәлебез белән дә нык бәйләнгән».*

*Менә шундый сүзләр әйтер идем. Инде ярамый дип тапсагыз, басмагыз, артык шомартуны теләмәс идем. Үзегезгә карагыз, Сез сорагач, язарга булдым. 60 еллыкка Яхъя Абдуллинны, мине дә чакырырбыз дигәнсез. Яхъя өйдә түгел, Казан тирәсендә ялда, ул кайтып йөри. Мин риза, шәт ул да кайтырга ризадыр дип беләм.*

*«Шәһри Казан» газетасының пробный саны чыгачак бүгениртәгә, игътибар итегез, анда минем бер әйбер басыла, шулай ук «Комсомолец Татарии»да да – икесе дә, миңа калса, бик проблемалы һәм нык кыю нәрсәләр.*

*Сәламнәр белән, тиздән очрашуга хәтле*

Әбрар.
7 август, 1990.

**P. S.** Саба РК КПССта 11 кеше генә калды дип язасыз. Озакламый ул үзе калырмы икән әле? Демократия белән берпартиялек бергә яши алмый бит...

***Тәлгат туган!***

*Сездән «Җиңү байрагы»ның 28 август саны килеп төште. Анда минем мәкаләмне, аңа матур итеп кереш язып бастыруыгыз, бу санны миңа җибәрүегез өчен чын күңелемнән зур рәхмәт.*

*Районыбызның 60 еллык бәйрәмен шундый матур оештыргансыз. Шәхсән миңа бик нык ошады. (Юбилей значогы костюмнан төшеп калган, бер данә таба алмассызмы икән?) Хакимият башлыгы Фәрит Гыйльмиев белән беренче мәртәбә таныштым. Ул миндә бик җылы тәэсир калдырды.*

*Үзем 17 сентябрьдә Ялтага, А.П. Чехов исемендәге Язучыларның иҗат йортына китәм.*

*Сез җибәргән юбилей материалларын Яхъя Абдуллинга тапшырдым.*

*12 сентябрь көнне ИЯЛИнең Гыйльми Советы дүрт кешене, шул исәптән мине – СССР ФАнең Член-корреспондентына тәкъдим итте. Мәскәүнең 73 елга әле бер генә татарга да академик исеме биргәне юк (ТАССРда эшләүчеләргә). Бу юлы да бирмәячәк, чөнки Фәннәр академиясе рус кулында, ә татарны ул җене кебек сөйми.*

*Мине искә алучыларга сәлам әйтегез. Машинкам эшләми, шуңа күрә кулдан язам.*

*Иң изге теләкләр белән*

Әбрар.

14. IX. 1990.

***Мөхтәрәм Тәлгат туган!***

*Бүген больницадан чыгуыма хат һәм Сезнең «Саба таңнары»нда басылган «Китап галиме» дигән мәкаләгез белән ул газета саны көтеп тора иде. Миңа булган даими игътибарыгыз өчен чиксез күп, зур рәхмәтләрем сезгә. Инде уйлап та куям: район газетасы битләрендә минем турыда еш язып, укучыларны туйдырмадыгыз микән, йә инде бу Кәримуллин бик әрсез, ахыры, гел аны басалар, үзе сорый торгандыр, мөгаен, диючеләр дә бардыр...*

*Больницага керүемнең сәбәбе: аяклар белән эш шәп түгел. Кайвакытта йөреп булмый, шуның өстенә буыннар да гел сызларга ярата – фронтта суык тигән, өшегән иде аяклар (аннан – атеросклероз нижних конечностей).*

*Миңа елына ике тапкыр шифаханәгә-сырхауханәгә керергә кирәк, профилактика йөзеннән. Врачлар шулай кушалар. Ә минем вакытым булмый, шуннан кризис килеп чыга.*

*«Шәһри Казан»да инде язганнар иде: мин Канадага җыенам. Анда июнь ахырында һәм июль башында XVIII Халыкара конгресс була – «Сәнгати, мәдәни һәм фәнни элемтәләр» дигән темага. Аны Англиядәге Халыкара биографик мәркәз белән АКШтагы Халыкара биографик институт үткәрә. Шулар мине персональ чакыралар. Минем турыда шушы ике Халыкара энциклопедия үзәге булган фәнни оешмалар үзләренең дүрт энциклопедияләрендә зур-зур биографик белешмәләр бирделәр. Тик хәзергә валюта ягы гына хәл ителеп бетмәгән. Татарстан Министрлар Советы валюта табарга, бирергә дип тора. Юл Монреальга самолет белән 1990 сум иде – совет акчасына, хәзер 6 меңгә күтәрелде. Бару мәсьәләсе катлауланды. Мин анда «Татар халкының мәдәнияте» дигән темага доклад белән катнашып, күренекле татар әдипләре, галимнәре, җәмәгать эшлеклеләре, бизнесменнары турында сөйләргә һәм аларны энциклопедияләргә кертү турында сүз алып барырга тиеш идем. Үзем Австралиядә штабы булган Халыкара Рыцарьлар Конференциясенең Үзәк шурасы әгъзасы буларак, анда да берничә татар кешесен рыцарьлыкка тәкъдим иттем. С. Алишевны инде үткәрә алдым. Тиздән Разил Вәлиев белән Равил Фәйзуллинны да кертерләр дип уйлыйм. Аларны кабул итүне сорап, тиешле документлар җибәрдем. Канадага бара алсам, ул энциклопедияләргә дә үз милләтебезнең күренекле кешеләрен үткәрүгә юл ачылыр иде.*

*Больницадан кайтуга, чит илләрдән берничә бандероль һәм хатлар көтеп тора икән. Берсе – Румыниядән. 17-19 майда Констанца шәһәрендә румын татарлары Мәхмүт Ниязи дигән румын татар шагыйренең вафат булуына 60 ел тулу уңае белән Халыкара симпозиум үткәрәләр икән. Шуңа катнашырга чакырып программа җибәргәннәр. Анда барып, Румыния татарлары белән элемтәне ныгыту бик кирәк тә, тик валюта дигән нәрсә тота, белешеп карыйм, нәрсә чыгар?*

*Мин үткән елны пенсиягә чыгып караган идем, яңадан кире чакырып алдылар. Хәзер хәтта ике урында эшлим: ИЯЛИдә һәм Үзәк фәнни китапханәдә консультант булып. Аннан бик күп җәмәгать эшләре, төрле җирләргә очрашуларга бару... Язасы нәрсәләргә тотынып та булмый диярлек, язылганнары «Идел» журналында, газеталарда озак ята... Минем язганнар төерле, әчкелт, шуңа күрә бик басабыз дип тормыйлар, курку әле дә яши аларда...*

*Иң ярамаганы: саулык җитеп бетми, шуңа күрә язасы әйберләр озакка сузыла.*

*Газета өчен кәгазь табу авыр дигәнсез, моңа Казанда да зарланалар. Төрле-төрле газеталар, халтуралар чыгып тора, аларга кәгазь бар... Монда мәсьәлә тирәнрәк ята дип уйлыйм. Ил зур киеренкелек алдында, аның законнары эшләми, консерваторлар, партократия каты һөҗүмгә күчте. Куркам, тора-бара хәлләр тагын да кискенләшәчәк. Шундый заманнарга калдык, Тәлгат туган, ахыры гына уң булсын иде татар өчен, милләтебез өчен.*

*Хатым озынга китте.*

*Бар изгелекләрегез өчен кабат рәхмәт, эшегездә, тормышыгызда уңышлар, сөенечләр генә теләп калам*

Әбрар.
19 апрель, 1991.

***Мөхтәрәм Тәлгат туган!***

*Кичә Күк-Түбәдән кайтып төштем. Язучыларның иҗат йортында булдым. Зәки Зәйнуллин, шагыйрә Эльмира Шәрифуллина, Фоат Галимуллин, Мәхмүт Хөсәен, Мәгъсүм Насыйбуллин – бер зур команда белән булдык. Болай яхшы гына ял иттек, эшләдек, Кырым туганнарыбыз – татарлар белән дә аралаштык, андагы хәлләрне белештек.*

*Кайтуга Сездән хат һәм «Саба таңнары» мине көтеп тора иде. Минем язмамны бастыруыгыз өчен, игътибарыгыз өчен бик зур рәхмәт.*

*Августта булган фетнә бер яктан кайбер мәсьәләләр буенча, бигрәк тә безнең, татарлар өчен авырлыклар тудырса да, СССР дигән империяне өч көн эчендә җимерелүгә китерде. Бу фетнә булмаса, СССР кайчан әле җимерелеп бетәр иде, моңа дистә ел кирәк булачак иде.*

*КПССның таркалуы да зур прогресс. Бу, әлбәттә, һәр КПСС әгъзасы начар кеше дигән сүз түгел. Сүз КПССның идеологлары, КПСС аппараты турында, аның эшчәнлеге турында бара.*

*Сез, райком секретарьлары Зөфәр Шәйхетдинов һәм минем сабакташым Гөлбикәнең улы хәзер ял итәләр, күңелләре тыныч түгел, дип язасыз. Мин аларны аңлыйм. Алар – яшь, таза, белемле кешеләр. Башларыннан коммунизм идеологиясе сөремен куалап чыгарсыннар да милли азатлык һәм халык ихтыяҗларына хезмәт итүгә керешсеннәр. Зөфәр – ул татар теле һәм әдәбияты укытучысы, тотынсын шушы эшкә. Бүген татар мәктәпләре өчен иң авыр нәрсә – кадрлар җитешми. Җаннарында иманнары булса, алар шуңа керешсеннәр. Башка өлкәдә дә аларга урын бетмәгән, ләкин мин халык мәгарифе бүген иң актуаль нәрсә дип саныйм. Түрә булган кешеләргә гади эшкә күчүе авырдыр, бәлки, ләкин мин монда бернинди яман нәрсә күрмим.*

*Бүген татар милләтенең язмышы хәл ителгән вакыт. Милли җаны булган һәр кеше шул турыда уйларга, шуңа хезмәт итәргә тиеш.*

*«Шәһри Казан»га язылырга үгетләп мәкалә язарга җитешмәм дип куркам. Кайтуыма бик күп эшләр җыелган. Җитешсәм, язам, әлбәттә. «Шәһри Казан» хәзер прогрессиврак. «Социалистик Татарстан»да хәзер җанга якын әйберләр бик аз. Исеме ни тора – «Социалистик» бит.*

*Миңа булган игътибарыгыз өчен, изгелекләрегез өчен чук-чук рәхмәт, иң изге теләкләрдә калам*

Әбрар.
17 октябрь, 1991.

***Мөхтәрәм Тәлгат туган, якташым!***

*Сездән «Саба таңнары» (13 октябрь, 1994) килде. Анда Сез минем турыда «Татарстан Фәннәр академиясе»ндә чыккан биографик белешмәне бастыргансыз. Бу, әлбәттә, Сезнең эш, үзегезнең инициатива буенча башкарылган. Сезгә мең рәхмәт. Кызганыч, Саба урта мәктәбенең юбилеена кайта алмадым. Тантана буласы көнне Төркиягә китәргә туры килде. Әле Мәгъсүм Хуҗинны күргән идем. Ул да бу юбилейга кайта алмаган. Күптән түгел Сабада булган. «Сөйләштем: икәүләп бер кайтып килербез, чакырып калдылар», – диде. Мәктәп чакырган дип аңладым. Анда бер очрашу үткәреп килергә рәхәтләнеп әзер. Көннәр язга авышкач, йә яз башында, йә язның үзендә. Аннан соң да, 1995 елда тагын Төркиягә чакыралар, фәнни конференциягә. Шулай ук лекция укырга Измир шәһәрендәге Эгей университетына да чакыралар. Бу киләсе уку елында булыр.*

*Төркиягә бару турында «Заман»да минем информация чыкты, шуның ксероксын җибәрәм. Сез «Заман» газетасын алмыйсыздыр. Бик кыска гына яздым ул информацияне. Безнең белән барган Фатыйх Урманчеевка зуррак итеп язарга кушылган иде, матбугатта күренмәде.*

*Якташ сынчыбыз Кадим Җәмитнең күргәзмәсендә озак була алмадык. Ашыгыч эш бар иде – Мирфатыйх Зәкиев тизрәк алып китте. Саба хәлләрен дә сораша алмадым.*

*Миңа киләсе елның май аенда 70 тула. Шул уңай белән Татарстан китап нәшриятында «Язмыш, язмыш…» дигән әсәрем ята. Нәшрият акча юк, басылуы икеле дип тора. Спонсор эзләргә кушалар. Эшләр гел шулай торса, әллә район башлыгыбыз Фәрит Гыйльмиевкә мөрәҗәгать итәргәме? Сез ничек карыйсыз? Минем гомеремдә кешедән бернәрсә сораганым юк, аңа мөрәҗәгать итү минем өчен үлем белән бер кебек.*

*Ни эшлисең, чыгармасалар чыгармаслар. Инде аныңише нәрсәгә күнеккән. Хәзергә көндә өч китабым басылмый ята, берни эшләп булмый.*

*Эшлисе эшләр күп, тик вакыт җитми, аннан сәламәтлек тә мактанырлык түгел. Дөньяны агартам, милләтне уятам дип йөреп, үзем каралып беттем инде. Тамагы тук булса, халыкка ике дөнья – бер морҗа, бигрәк тә безнең татар халкына. «Саба таңнары»н очраганда карарга тырышам. Аның яңа саннарын укыгач, туган якларга кайткан кебек булам. Газета үзенең эчтәлеге белән шактый мавыктыргыч чыга. Сезгә «Афәрин»нән башка сүз юк. Республика газеталарында да сезнең мәкаләләрегез күренеп тора, моның өчен дә рәхмәт. Тик кенә ятмыйсыз, Саба патриотизмы тәрбиялисез. Сезгә яңа уңышлар, сөенечләр теләп, рәхмәт белән*

Әбрар Кәримуллин.
10 ноябрь, 1994.

*Тәлгат туган!*

*Крутушкадан язган хатыгызны алдым. Минекен дә алгансыз икән. Мин аны ашыгыбрак язган булып чыктым. Минем «Язмыш, язмыш...» дигән кулъязманы Татарстан китап нәшрияты 1995 ел планына керткән. Президентыбыз киләсе елга Ватан сугышы тәмамлануга 50 ел тулу уңае белән барлык фронтовик язучыларның нәшриятка тапшырган әсәрләрен басарга акча бүлеп бирәчәген белдерде. Нәшрият директоры, шәт инде, Президент кушканны эшләр дип уйлыйм.*

*Шуңа күрә Фәрит әфәнде Гыйльмиевкә мөрәҗәгать итеп торуның кирәге бетте. Сайлаулар уңае белән аның турында бер-ике сүз әйтергә мин риза. Ләкин бит мин аның турында нәрсә булса да әйтү өчен ниндидер конкрет фактларга таянырга тиеш. Әгәр Сез миңа шундый фактларны хәбәр итсәгез, эш миннән тормас. «Болванка» язып җибәрсәгез, бигрәк тә яхшы булыр иде.*

*Соңгы вакытта сәламәтлек шәптән түгел. Менә ике атна авырып алдым. Минем квартирам бик салкын, суык көннәрдә идәндә су ката. Алыштыруда ярдәм итүләрен сорап караган идем, зур түрәләребез үтенечемне отфутболить кына итте. Мин тормышта практичный кеше түгел.*

*Милләт, милләт дип янып йөрүләремнең нәтиҗәсе күренмәгәч, матбугатта аны яклап язуларның кирәге, файдасы күренми дип, бу эштән читләшә башладым. Бу соңгы өч-дүрт елда публицистика белән генә диярлек шөгыльләндем, күпме фәнни хезмәтләр язылмыйча калды. Аларны язып та татарны уятып булмый, булмас ахры. Хәзер күңелнең иң төшенке вакыты. Шартнамә милләтне элекке коллык хәлгә кайтарды.*

*Бәлки истәлекләр язарга керешермен. Минем тормыш гаять авыр һәм катлаулы булды, әле дә шулай. Әйтер сүзләр өелеп тора. Бу өлкәдә бер тәҗрибә дә ясап караган булдым. Октябрьдә мин дә ялда, Бәкер санаториясендә булдым. Шунда Табеев белән «дуслыгыбыз» турында бер истәлек язып, бер журналга тапшырдым. Кешеләргә ошаса, истәлекләр язуга кучәрмен, бәлки. Анда, әлбәттә, Сабага да урын булыр, чөнки ул минем тормышымда шактый зур роль уйнады.*

*Алдан кычкырган күкенең башы авырта, диләр. Шулай булып чыкмаса ярар иде. Сәламәтлек кирәк.*

*Тәлгат туган, игътибарыгыз, җылы, деловой хатыгыз өчен зур рәхмәт. Сезне, гаиләгезне (хатыныгызның исемен дә белмим бит) Яңа 1995 ел белән котлыйм, барыгызга да саулык-сәламәтлек, бик кирәкле эшегездә, Сабаны республика күләмендә пропагандалауда да шулай тырышып эшләвегезне теләп калам.*

*«Саба таңнары» газетасы коллективын да чын күңелдән Яңа 1995 ел белән тәбрик итәм, бәхетле булыгыз, саулык-сәламәтлек сезгә, барыгызга да.*

*Олы ихтирам белән райондашыгыз*

Әбрар.
Декабрь, 1994.



Саба төбәге мәшһүрләре – галим Ә.Кәримуллин һәм артист Ш.Биктимеров.1999 ел

***Мөхтәрәм Тәлгат туган!***

*Хакимиятебез башлыгы турындагы «Мин дә яклыйм» дигән (сайлаулар уңаеннан) язманың күчермәсен Сезгә салам. Бер данәсен, киңәшегезне искә алып, «Ватаным Татарстан»га җибәрәм. Басу-басмауларына минем йогынты ясый алмавымны алдан ук белдерәм. Анда Теләче егете Нургали Булатов бар, аңа әйтеп карармын. Бәлки бу язманы «Саба таңнары»нда басарсыз, «В.Т.»да кабат чыга икән, моның зыяны булмас.*

*Ихтирам белән*

Әбрар.
25 январь, 1995.

***Мөхтәрәм Тәлгат туган!***

*Күптән түгел генә бер китабым басылган иде, шуны Сезгә юлларга ашыгам. Шактый гына вакыт больницада ятып чыктым, шуңа күрә җибәрергә бераз соңгарак калдым.*

*Сезнең матбугатта басылган, ТВ, радио аша булган чыгышларыгызны яратып укыйм, карыйм, тыңлыйм. Шул минутларда үземне туган ягымдагы кебек хис итәм, күңелләр йомшарып китә. Алар миңа туган ягымнан сәлам булып яңгырый. Шундый сәламнәрегез күбрәк ишетелеп торсын!*

*1997 ел минем һәм гаиләм өчен бик авыр булды. Терекөмеш белән агуларга тырышулар һәм аның нәтиҗәләре әле дә нык сиздерә.*

*«Туры әйткән туганына ярамаган» дигән мәкальнең ни хәтле хак икәненә тагын бер мисал бу хәл.*

*Сез Саба районына багышланган китап әзерлисез икән. Бик кирәк эш башлагансыз. Миңа бер фотосурәтче шалтыраткан иде, районлаш артистыбыз Шәүкәт Биктимеров белән бергә рәсемгә төшерербез, дигән иде. Шул кеше әйтте. Башка районнарның кайберләре хәтта энциклопедияләренә керешкән икән, сезнең эшне дә мин шуның белән тиңлим. Аңлыйм, мондый эш башкару өчен ай-һай күп хезмәт кирәк, күп тикшеренүләр кирәк. Башлап җибәрү үзе үк зур каһарманлык, моның өчен зур рәхмәт.*

*«Саба райондашлык» җәмгыятен төзүгә керешүдә актив катнаша башлаган идем, чирләп китү, килеп чыккан фаҗигадәй хәлләр аркасында читләшергә мәҗбүр булдым: авырып торгач, ни эшли аласың. Шәт, киләчәктә гел шулай булмас, дип ышанасы килә.*

*Соңгы вакытта «Мы не пыль на ветру» («Без тарихта эзлебез») дигән хезмәт өстендә эшлим. Инде кырыйлары күренә башлады. Бер 400-450 бит чыгар ахры. Бастыру өчен спонсор эзлим. «Тел– милләтнең сакчысы» дигән китап та спонсор ярдәме белән басылды.*

*Ул китапны яратып каршы алдылар. Әгәр кирәк тапсагыз, «Саба таңнары»нда шуның берәр өлешен бастыра аласыз, анда күтәрелгән мәсьәлә милләтебезнең иң авырткан җире турында. Шуның өстенә берсе «Три Сосны», «Два поля Арташ», «Богатые Сабы» кебек тәрҗемә исемнәргә дә карый. Анысын үзегез карагыз, болай гына әйтүем.*

*Бандероль белән бу китапны ике данә җибәрәм. Берсен район музеена бирсәгез, яхшы булыр иде.*

*АКШтан Яңа Орлеан шәһәреннән Халыкара конгресска чакырганнар, август ахыры – сентябрь башында булачак. Аны энциклопедик белешмәләр чыгаручы ике Халыкара оешма үткәрә. Катнашу өчен һәм юл өчен шактый долларлар кирәк, ярдәм итүче килеп чыкса, барырга дип торам. Анда ясаячак докладның тезисларын җибәрдем.*

*Болары инде Сезнең өчен кызык та түгелдер, сүз чыккач кына әйтүем.*

*Хакимят башлыгыбыз Фәрит Гыйльмиевне мин хөрмәт итә идем, аның китүе минем өчен аяз көнне яшен суккан кебек булды.*

*Җәен туган авылыма кайтырга планлаштырып торам. Дөрес, анда инде туганнар юк. Кайта алсам, газета редакциясенә дә сугылып китәргә тырышыр идем. Яңартылган, манара куелган Саба мәчетен дә (1841 елгы) күрәсем килә.*

*Сезне Иске Яңа ел, 1998 ел белән тәбрик итәм. 1997 елдагы кебек шулай актив эшләвегезне, Саба исемен дөньяга танытуда зур уңышлар, тормышыгызда бәхетләр теләп калам.*

*Тирән ихтирам белән*

Әбрар.
12. 01. 1998.



**Йомгаклау сүзе**

Менә, хөрмәтле укучыларыбыз, халкыбызның йөзек кашы булган академигыбыз Әбрар Кәримуллинның туган ягына язылган хатларының сакланганнары белән таныштыгыз. Үзе китте, әмма Әбрар ага өчен төп кыйбласы – туган теле – байлыгы да, Ватаны да, мәгарифе дә, мәдәнияте дә, дине дә булган титан хезмәте, гомумән, күпләгән китаплары, меңләгән кульязмалары, хатлары калды. Туган авылы зиратында җәсәде ята. Мин, җай килгән саен, ягъни, юлым Чәбия-Чүрчи якларына төшкәндә Аның янына сугылам. Һәм шунда – тыптын зиратта якташ шагыйрәбез Флера Тархановaның (әнисе Байлар Сабасыныкы) шигъри юллары искә төшә.

*... Әле кичә генә көлә-көлә*
*Кайтып киттең бит*
*син югыйсә.*
*Ә бүгеннән сине суырып алган*
*Кабер өсләрендә гөл үсә.*

**Тәлгат НӘҖМИЕВ,**
*язучы, журналист,*
*1981–2008 елларда*
*«Саба таңнары» газетасы*
*мөхәррире*

В сентябре 2000 года не стало известного татарского ученого книговеда, доктора филологических наук, академика АН РТ А.Г. Каримуллина.
В статье Т. Назмиева предлагается подборка писем А.Г. Каримуллина, адресованных автору, в которых поднимаются такие темы, как любовь к родине, национальный вопрос, научная деятельность и др.

# ПОДАРИМ ДЕТЯМ РАДОСТЬ




**Семья. Мама. Папа. Домашний очаг... Для многих детей эти слова - обыденность, само собой разумеющееся, но не для всех. Совсем другое значение этим словам придают дети, воспитывающиеся в детских домах, интернатах. В этих словах для них боль, надежда, мечта о счастливой жизни в семье.**

Во всём мире проблемам брошенных детей, детей-сирот уделяется большое внимание, она одна из основных и самых болезненных. Несомненно, в первую очередь, на помощь этим детям приходит государство. Для таких детей у нас существуют детские дома, интернаты. Но государство может только создать условия для развития человека, что важно, но недостаточно, так как главную роль в личностном становлении играет только семья, родители. Именно в семье дети получают шанс полноценно расти и быть счастливыми.

В настоящее время проводится большая работа в поддержку приемных семей, благодаря этому многие дети находят своих приёмных родителей, и это очень положительная тенденция. Но есть детские дома и интернаты, где живут дети с ограниченными физическими возможностями, которым гораздо тяжелее найти приёмных родителей. А им также хочется внимания, заботы, тепла и знать, что они кому-то нужны… Потенциальные родители боятся трудностей, ведь в этих детей надо вкладывать гораздо больше сил, терпения, любви, да и средств тоже. И поэтому чаще всего эти дети живут в специализированных детских домах, а затем до конца жизни остаются в домах для инвалидов.

Но это не значит, что их жизнь совершенно ограничена и они одиноки.

Судьбы этих детей не безразличны многим: у них появляются спонсоры, создаются различные благотворительные фонды, им помогают просто неравнодушные люди.

Сотрудники Республиканской юношеской библиотеки Татарстана знают о проблемах этих детей не понаслышке. Библиотека на протяжении многих лет дружит с Казанской специальной (коррекционной) общеобразовательной школой-интернатом №4 VI вида Советского района г.Казани. В этом учреждении живут и учатся дети с нарушениями опорно-двигательного аппарата. Большая часть детей, проживающих в интернате, имеет семьи. И это далеко не всегда семьи, деградировавшие или нежелающие воспитывать ребёнка, чаще это семьи, не имеющие для этого ресурсов и возможностей. Но также здесь живут дети, оставшиеся сиротами, или дети родителей, лишенных родительских прав. Помимо чудовищного стресса от потери семьи, который и у здоровых детей вызывает отставание в развитии, дети с «диагнозами» страдают еще и от своей болезни.



*Е.В. Гусева презентует фотоальбом*



*Кобякова Генриетта Лукинична (в центре)*

Ситуация для такого ребёнка тяжела вдвойне. Но они учатся с этим жить. У них сложился свой особенный мир, здесь они на равных, они поддерживают друг друга. Трудно представить, насколько сложен мир ребенка, лишенного родительского внимания и отягощенного физическим недугом…А преподаватели и воспитатели интерната заботятся о них, стараются подойти к каждому с пониманием, с поддержкой.

В специальной школе-интернате №4 созданы хорошие условия для учёбы и проживания ребят. В новом здании удобные кабинеты, просторные спальни, есть тренажёрный зал, хорошая столовая. И, конечно же, есть кабинеты для прохождения необходимых медицинских процедур, которые многим ребятам нужны ежедневно.

Они живут в интернате, который стал для некоторых родным домом, а воспитатели – родными, близкими людьми. Хотя это не так просто. Не каждый человек сможет работать с больными детьми. В этом случае необходимы самые простые, но и самые дефицитные в наше время качества характера: доброта, терпение, сочувствие, но самое главное – это любовь.

Воспитатели прикладывают все усилия, чтобы вырастить образованных, порядочных людей, сформировать личность, что в условиях интерната очень трудно сделать. Воспитатели полностью отдают себя детям, все свои силы и время. В этом интернате все сотрудники работают с душой, но есть среди них преподаватель русского языка и литературы Генриетта Лукинична Кобякова, которая работает в интернате уже более 40 лет. Она до сих пор энергична, полна разных идей. Она просто любит этих детей, и дети отвечают ей тем же. Многие дети относятся к ней, как к своей маме, ведь её большого сердца хватает на всех.

Генриетта Лукинична старается воспитать в детях силу воли, терпение, стойкость к жизненным ситуациям, порядочность. Она организовала в своём кабинете музей «Мужество», в котором собраны истории известных людей, ставших инвалидами, но не потерявших веру в себя, преодолевших физический недуг и продолжающих активную жизнь и общественную деятельность. И когда ребёнок видит, что он не один такой и есть реальные примеры, на которые можно равняться в сложной ситуации, то он становится сильнее и понимает, что бояться нечего, а надо жить, не отчаиваться и смотреть в будущее позитивно.

Воспитанники Генриетты Лукиничны по мере возможности посещают музеи, театры г.Казани. Многие приезжие артисты выступают в стенах самого интерната. Больше того, она организует для своих подопечных экскурсии по городам Республики Татарстан и России. Благодаря ей дети входят в большой мир, и даже физические недуги не мешают им жить полноценной жизнью.

За все эти годы у Республиканской юношеской библиотеки сложились дружеские и деловые отношения со специальной школой-интернатом №4. Было организовано большое количество мероприятий и добровольческих акций, цель которых – нравственное воспитание детей, раскрытие их интеллектуальных и творческих способностей, возможность сделать их жизнь насыщенней, интересней, подарить ребятам душевное тепло и доброту.

Ребята всегда активно участвуют и с благодарностью принимают эти мероприятия: мультимедийные программы, ретро-путешествия, «Видеоуниверситет искусств», «Краевед-экспресс», изовикторины, интеллектуальные игры, часы Высокого Искусства, часы интересных сообщений, экскурсии по выставкам работ молодых художников, информационно-познавательные программы, видеопрезентации, показы фильмов и др. Дети всегда любознательны, открыты для общения, для новых знаний. Каждый раз после проведения ме-

роприятий библиотека организует благотворительные акции: дарит детям книги, журналы, одежду.

Одними из масштабных мероприятий с воспитанниками интерната в практике библиотеки являются республиканские заочные литературные конкурсы эрудитов, организуемые совместно с газетой социальных проблем «Выбор». Целью конкурсов является приобщение молодежи с ограниченными возможностями здоровья к чтению, пропаганда произведений русской классики, произведений местных авторов и краеведческих знаний, расширение кругозора, эрудиции.

Первый конкурс «Пока в России Пушкин длится, метелям не задуть свечу» был посвящён 200-летию со дня рождения А.С.Пушкина. Затем последовали такие конкурсы, как: «И мира не узнаешь, не зная края своего» (о традициях и обычаях татарского народа), «У нас одно Отечество» (о традициях и обычаях народов Поволжья), «Я в книгу устремляю взгляд» (об истории татарской книги), «Быть сильнее судьбы» (о людях с ограниченными возможностями здоровья – героях спорта, деятелях культуры и искусства), «Краеведческая мозаика» (о флоре и фауне Татарстана), «Сказанием встает Казань» (об архитектуре Казани), «Литературный дилижанс» (по творчеству русских и татарских писателей), «О, спорт, ты – мир!» (посвящённый Универсиаде–2013), «Лев Толстой и Толстые в Казани» (к завершению десятилетия Л.Н.Толстого и 100-летию со дня его смерти) и др.

Так, в конкурсе на лучшее письмо-объяснение в любви к матери «И все-таки лучше всех на свете мама», который был организован библиотекой в преддверии Дня матери, одной из победительниц стала ученица 11-го класса Гульнур Сайфутдинова за письмо, адресованное воспитательнице, заменившей ей родную маму, – «Любимая, драгоценная, милая моя мамочка». Ей вручена книга «Сокровища Золотой Орды» и диплом за оригинальное и искреннее выражение своих чувств.

В 2015 году в рамках Года литературы состоялся очередной конкурс «Времён отдаленных дитя и певец», посвященный 130-летию со дня рождения поэта В.В. Хлебникова. И на этот раз в конкурсе успешно участвовали воспитанники интерната. С. Попов, Д. Вахитов, И. Тегенев – наши постоянные участники. У этих ребят всегда нестандартный подход к выполнению заданий, оригинальные мысли, что особенно ценно.

Каждый раз после завершения очередного конкурса сотрудники библиотеки приезжают в интернат, чтобы в торжественной обстановке поздравить ребят, сказать им тёплые слова поддержки и одобрения. В актовом зале в присутствии воспитанников интерната им вручают благодарственные письма и небольшие сувениры.

Очень приятно видеть радостные и счастливые лица ребят. Мы уверены, что их желание участвовать в конкурсах, их активность являются результатом нашей постоянной работы, нашего внимания и доброго отношения к ним. Очень важно при общении с детьми с ограниченными возможностями здоровья проявлять особую деликатность, внимание и профессионализм. С этим в полной мере справляются сотрудники РЮБ при проведении для воспитанников интерната разных мероприятий. Особую благодарность заслуживают специалисты Е.В.Гусева и К.Б.Ильязова, которые на протяжении многих лет сотрудничают с данным интернатом. Их знают и уважают преподаватели, а ребята всегда радостно их встречают.

В апреле 2016 года в рамках «Весенней недели добра – эстафеты добрых дел» была проведена интеллектуальная игра «Лишних знаний не бывает». В игре приняли участие учащиеся 10, 11, 12-х классов (в интернате предусмотрено 12-летнее обучение). Были организованы три команды «Умники», «Веселые ребята» и «Виктория». Ребята



*Команда «Веселые ребята»*



*Команда «Виктория»*




*Организаторы интеллектуальной игры Ильязова К.Б., Гусева Е.В., Аглиуллин И, Галкина Д.Р.*

серьёзно готовились к игре: просматривали книги из серии «Все обо всём», «Что? Где? Когда?», следили за последними новостями.

Игру провел руководитель молодёжного интеллектуального клуба «МИК» Ильдар Аглиуллин, ему помогали сотрудники библиотеки. Клуб «МИК» существует в юношеской библиотеке уже более двадцати лет. Команды клуба одержали немало побед в чемпионатах по играм «Что? Где? Когда?» и «Брейн-ринг» регионального и российского уровней.

Состязание состоялось по типу игры «Брейн-ринг». Участникам команд было задано двадцать вопросов, касающихся самых разных областей знания: литературы, биологии, спорта, кино. За одну минуту надо было найти правильный ответ, проявив не только знания, но и смекалку, сообразительность, находчивость. Ребята быстро и четко справлялись с заданиями, часто давали досрочные ответы. Почти все вопросы, а многие из них были непростые, каверзные, оказались под силу всем трем командам.

Участников команд поддерживали болельщики – учащиеся школы. Игра прошла динамично, легко и даже весело. Лица ребят буквально светились от счастья, когда они узнавали, что их ответ на вопрос правильный. Все три команды выразили желание еще раз стать участниками такой увлекательной игры, где можно показать свой интеллект и умение работать сообща, в команде.

В любой игре всегда есть лучшие из лучших. Победителем игры стала команда «Виктория» (11 класс), второе место заняла команда «Веселые ребята» (12 класс), третье место досталось команде «Умники» (10 класс). Всем трем командам от библиотеки были вручены почетные дипломы и подарки – фотоальбомы, где будут отражены самые важные и интересные события из жизни школы, класса. В этих альбомах обязательно будут фотографии с этой игры: ее команд, капитанов, ребят из группы поддержки. Глядя на их лица, будут вспоминаться судьбы каждого из них…

Так, капитан команды «Весёлые ребята» Сергей Попов учится на отлично, «идёт» на золотую медаль, он мечтает продолжить свое обучение в институте. Сергей принимает активное участие во многих библиотечных мероприятиях. Трагедия, произошедшая с его родителями, в результате которой он стал сиротой, не сломила его, у него далеко идущие планы на жизнь.

После завершения мероприятий всегда приятно видеть благодарные лица ребят, которые знают, что впереди будет ещё много добрых, интересных встреч и открытий… ■

**Дина ГАЛКИНА,**
*главный библиотекарь Республиканской юношеской библиотеки РТ*



*Команда «Умники»*

Татарстанның Республика Яшүсмерләр китапханәсе күп еллардан бирле Казандагы 4 нче махсус мәктәп-интернат – гомуми белем бирү һәм коррекцион уку йорты – белән тыгыз хезмәттәшлектә тора. Әлеге йортта терәк-хәрәкәт әгъзалары зәгыйфьләнгән балалар яши, укый, тәрбияләнә. Китапханәчеләр яшь дуслары өчен бик күп төрле мәдәни һәм танып-белү чаралары үткәрә. Йөрәк җылысы, ихлас кайгырту белән сугарылган аралашулар балаларга рухи ныклык, киләчәккә өмет-ышаныч өсти...



# «ГЛОБАЛЬНАЯ СЕТЬ: ЗЛО ИЛИ БЛАГО?»

**(ИТОГИ РЕСПУБЛИКАНСКОГО СОЦИОЛОГИЧЕСКОГО ИССЛЕДОВАНИЯ)**

Компьютерные технологии стали неотъемлемой частью нашей жизни, особенно молодежи. Несмотря на безусловную положительную роль, которую коммуникационные средства и Интернет играют в нашей жизни, существует определенный риск при их использовании. Психологи утверждают, что неумение контролировать качество и объем информации приводит человека к информационному стрессу, что чревато социальными последствиями и проблемами со здоровьем. Все чаще стало звучать слово «Интернет-зависимость». Эта зависимость перешла в разряд проблем общества и стала настолько значимой, что ее обсуждают даже на Интернет-форумах.

Хотелось бы понять, насколько быстро современная молодежь адаптируется в новых условиях, не устарели ли сегодня для молодых общепринятые понятия общения, насколько высок уровень Интернет-зависимости молодежи, какова роль Интернет-ресурсов в ее жизни? Объединяет или разъединяет молодежь виртуальная жизнь? Смогут ли библиотеки конкурировать с Интернетом, использовать его себе на пользу? Насколько правомерны выводы ученых и исследователей по этим вопросам? Соотносимы ли они с ситуацией, которая сложилась в Республике Татарстан?

Актуальность данных вопросов и необходимость определения методов их решения обусловила проведение ГБУК Республики Татарстан «Республиканская юношеская библиотека» с 1 февраля по 1 мая 2016 года анкетирования молодежи республики, результаты которого легли в основу социологического исследования «Интернет-зависимость – проблема молодежи?». Для проведения исследования была разработана анкета, состоящая из 25 вопросов. Вопросы содержали варианты ответов, которые респондент отмечал на свое усмотрение (один или несколько). Анкета также давала возможность респонденту высказать свою точку зрения на данный вопрос.

В исследовании участвовало более 690 респондентов: читатели ГБУК РТ «Республиканская юношеская библиотека», читатели 25 Централизованных библиотечных систем Татарстана, а также учащиеся специальной средней школы-интерната №4 г.Казани, пользователи социальной сети «ВКонтакте». По возрастному составу преобладали молодые люди в возрасте от 15 до 20 лет (61%), 20-30-летние респонденты составили 39%. Почти две трети респондентов – девушки (60%), 40% – юноши. Из них: 34% – респонденты с незаконченным средним образованием, 18% респондентов имеют среднее образование, 17% – респонденты со средним специальным образованием, 9% – студенты вузов. 16% респондентов имеет диплом о высшем образовании. В исследовании участвовали учащиеся средних школ, лицеев, колледжей, студенты вузов, служащие и рабочая молодежь. Преобладающая часть респондентов – жители небольших городов, сел и деревень республики. В ходе обработки анкет были получены интересные данные, которые позволили сделать определенные выводы.

Исследование показало, что более половины респондентов являются активными Интернет-пользователями, то есть проводят там большую часть своего свободного времени. Из этого следует, что молодежь предпочитает получать нужную



ей информацию из Интернета, считая такой способ для себя наиболее удобным и мобильным. Около трети респондентов получают необходимые сведения через общение с друзьями и знакомыми. Незначительная часть респондентов обращается в поиске нужных данных к книгам и специализированным изданиям.

Более всего молодежь привлекает в Интернете общение в социальных сетях, которое создает возможность обратной связи между пользователем и предоставившим информацию субъектом, а также анонимность, возможность выступать в роли, невозможной при общении в реальной среде. Около трети респондентов любят смотреть в Интернете видеоролики или фильмы. 100 респондентов используют Интернет для компьютерных игр.

